## ВАТАН ХАКЫ
Туган илне яратырга кирәк

> 15

## КРЕДИТ КАНИКУЛЫ
Аны ничек алырга?

> 16

## НӘФИСӘ САБИРҖАНОВА:
«Упкын читендә басып торганмын»

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 33 (28806) | Җомга | 11 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

«Татар-информ» / Владимир Васильев

# АШ БУЛСЫН!

## АЗЫК-ТӨЛЕК ЗАПАСЫ ҖИТӘРЛЕК

**Бу көннәрдә әйтерсең дөнья күчәре шикәр, он, карабодай, көнбагыш мае тирәсендә әйләнә. Сатучылар товарларны киштәләргә тезеп тә өлгермиләр, халык аларны бушатып та куя. Шунлыктан күпчелек кибетләр бер кулга бирелә торган продукция күләмен чикләргә мәҗбүр булды. Шул ук вакытта белгечләр, товарларга кытлык юк, бәяләрдә дә тотрыклылык саклана, дип ышандыра. «ВТ» хәбәрчесе азык-төлек базарындагы гомуми вазгыятькә күзәтү ясады.**

> 6

Ишетми калмагыз

## Авыручылар кими

Россиядә коронавирус йоктыручылар саны кими. Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова белдергәнчә, узган атнада 100 мең кешегә 420,01 чирләүче туры килгән. Бу – алдагы атнадагыга караганда 29,6 процентка кимрәк. Шул ук вакытта, Попова сүзләренә караганда, коронавирус йоктыручыларның 97 проценты чирне ОРВИ кебек яки бернинди билгеләрсез уздыра.

Соңгы тәүлектә Татарстанда янә 717, шул исәптән Казанда 231 кеше коронавирус йоктырган. Шулардан 119ы – балалар. 83 кешене хастаханәгә салганнар. Пандемия чорында барлыгы 128718 коронавирус очрагы теркәлгән.

Республикада барлыгы 2473995 кеше вакцина ясаткан. 258551 кеше ревакцинация узган.

## *Түләүләрдән азат итәргә*

Россиядә күпбалалы гаиләләргә торак-коммуналь хезмәтләр хакының 100 проценты күләмендә субсидия бирелә башларга мөмкин. Бу хакта «Известия» газетасы хәбәр итә. Дәүләт Думасының Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе урынбасары Светлана Разворотнева әйтүенчә, әлеге чара эшсезлек җиле кагылган гаиләләргә карата да кулланылырга мөмкин. Моннан тыш 65 яшьтән өлкәнрәкләргә ТКХ бәясенең 70 проценты күләмендә субсидия кайтару, торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә банк комиссиясен бетерү тәкъдим ителә. Тәкъдимнәрне Россия Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына юллаганнар.

## Чит илләргә чыгару тыела

Хөкүмәт Россиядән чыгару вакытлыча тыелган товарлар һәм җиһазлар исемлеген раслаган. Әлеге карар ил базарында тотрыклылыкны тәэмин итү өчен кабул ителгән, дип аңлатыла. Тыю 2022 ел азагына кадәр гамәлдә булачак. Исемлеккә технологик телекоммуникация, медицина җиһазлары, транспорт чаралары, авыл хуҗалыгы техникасы, электр аппаратурасы әләкән. Гомумән, анда барлыгы 200 атамадан артыграк товар, шул исәптән тимер юл вагоннары һәм локомотивлар, контейнер, тимер һәм таш эшкәртү станоклары, монитор һәм башкалар урын алган. Бу товарларны, Евразия икътисади берлеге (ЕАЭС), Абхазия һәм Көньяк Осетиядән тыш, барлык чит илләргә чыгару вакытлыча тыела.

Районнарда ни хәлләр?

**Арча**

«Россиянең студентлар гүзәле – 2022» исеменә Арчада туып-үскән Камилла Прахова лаек булды. Җиңү өчен илнең 44 төбәгеннән 56 студент көч сынашты. Камилла Арчаның 1 нче мәктәбен тәмамлаган, хәзерге вакытта Казан илкүләм технология тикшеренү университетында белем ала. «Мин җиңүемә әле дә ышана алмыйм. Күз яшьләре бәреп чыкты хәтта», – ди Россиянең иң гүзәл студенты. Камилла «Россия студентлар язы» XXX фестиваленең ачылу тантанасында катнашачак. Ул 18 майда Самара шәһәрендә узачак.
(«Арча-информ»)

**Кукмара**

Кукмара шәһәренең Гафиятуллин урамында «Социаль ипотека» программасы нигезендә төзелгән 40 фатирлы йорт ияләренә тапшырылды. Әлеге йорттан фатирларның егермесе – бюджет системасында хезмәт куючыларга, өчесе – табибларга, тугызы – ятимнәргә, ә сигезе биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләргә бирелде. Саннарга күз салсак, районда 2013 елда – 30, 2014тә – 22, 2015тә – 23, 2017дә – 8, 2018дә – 1, 2020 елда 11 гаилә әлеге программа буенча сафка баскан яңа йортларда өй туйлары уздырган. Киләчәктә шәһәрнең Тимер юл һәм Эшчеләр тыкрыгы урамнарында да яңа йортлар төзү планлаштырыла.
(«Хезмәт даны»)

**Яшел Үзән**

Олег Кучумов крестьян-фермер хуҗалыгы җиләк-җимеш культуралары үсентеләрен җитештерү өчен Яшел Үзәндә биоүзәк ачарга телИ. «Без заманча биоүзәкнең пилот проектын эшлибез. Анда җиләк-җимеш культуралары үсентеләрен җитештерүнең тулы циклы булачак. Югары сыйфатлы, сәламәт һәм уңыш бирүчән үсентеләр үрчетергә телибез. Биоүзәк микро-клонлаштыру лабораториясе, җылытыла торган теплицалар, питомник һәм үстерү мәйданнарыннан торачак», – дип сөйләде хуҗалык әгъзасы Екатерина Кучумова. Аның сүзләренчә, җитештерелгән үсентеләр импорт товарларын алмаштыра алачак. Биоүзәк Яшел Үзәндә булачак, биш агрозонада да бүлекләр булуы каралган.
(«Татар-информ»)

**Зәй**

Районда оешма-предприятиеләр, учреждениеләр арасында Зәйнең 370 еллыгы уңаеннан «Җир йөзендәге иң яхшы шәһәр» дип исемләнгән шәһәр үзешчән иҗат фестивале башлана. Фестивальдә мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, мәктәпләр, политехник колледж, оешма-предприятие коллективлары катнаша. Бәйге нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр дипломнар һәм сертификатлар белән бүләкләнәчәк. Приз фонды Зәйнең 370 еллыгы уңаеннан 370 мең сум тәшкил итә. Гран-прига лаек булучылар 100 мең сумлык сертификат белән бүләкләнәчәк.
(«Зәй офыклары»)

# ЯРЫШ БЕТМИ

**Спорт**

**Бу җиңүләр соңгысы булмаячак! Казан Кремлендә Пекинда узган Кышкы Олимпия уеннары призерлары һәм паралимпиячеләр белән очрашуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әнә шулай диде.**

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Олимпия уеннарында нейтраль статуста чыгыш ясауларына һәм басым зур булуга карамастан, спортчылар осталык, максатчанлык күрсәтә алдылар.

– Сезнең ярдәм белән Татарстанның спорт тармагы кышкы төрләрне үстерүгә яңа этәргеч ала, – диде Президент. – Татарстанны данлаучы спортчылар һәм тренерлар белән горурланабыз. Алда әле сезне бик күп җиңүләр көтә. Сез киләчәктә дә безгә онытылмаслык хис-кичерешләр бүләк итәчәксез, республика һәм илнең спорт казанышлары тарихын тулыландырачаксыз.

Аның сүзләренә караганда, бу уңышлар – тренерларның, спорт федерацияләренең, клубларның һәм оешмаларның уртак тырышлыгы нәтиҗәсе. Ул спортчыларның туганнарына һәм якыннарына да рәхмәт әйтте. «Сезнең өчен бөтен ил җан атты! Сезнең нәтиҗәләр республикадагы спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче 90 меңнән артык малай һәм кызны тагын да ныграк рухландырачак», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент әйтүенчә, республикада спорт белән шөгыльләнү, балаларны спортка җәлеп итү өчен алга таба да шартлар булдырылачак. «Соңгы вакыйгаларга карамастан, без спортчыларыбызга һәрьяклап ярдәм күрсәтергә ниятлибез. Илдә халыкара зур ярышлар уздырмау, Россия спортчыларын ярышлардан читләштерү спорт тармагына зыян салырга тиеш түгел. Безнең спортчыларның әзерлек дәрәҗәсен саклап калу өчен мөмкин булганның барысын да эшләячәкбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, Татарстаннан Рушан Миңнегулов һәм Марта Зәйнуллина Пекинда Паралимпиадада чыгыш ясарга тиеш иде. Әмма спорт түрәләре сәяси карар чыгарып, Россия спортчыларын ярышка кертмәде. Казан Кремлендә узган очрашуга Рушан белән Мартаны да чакырдылар. «Сез мактауга лаек. Сезгә карата кабул ителгән гаделсез карар ихтыяр көчен сындырмасын. Без сезне яклау өчен бөтен көчебезне куячакбыз һәм кирәкле ярдәмне күрсәтәчәкбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Билгеле булганча, Пекин Олимпиадасына Татарстаннан 8 спортчы барды. Шулардан бишесе медальләр алып кайтты. Казан кызы Евгения Тарасова иптәше Владимир Морозов белән спорт парлары ярышында икенче урынны алды. Ул гына да түгел, алар беренче урындагы Кытай спортчыларыннан нибары 0,62 баллга калыштылар. Лениногорск егете Данил Садриев трамплиннан сикерү буенча команда ярышларында иптәшләре белән икенче урынны алды. Россия спортчыларының спортның бу төрендә 54 ел дәвамында медаль ота алганы юк иде. «Ак барс» хоккейчылары Тимур Билалов белән һөҗүмче Дмитрий Воронков Пекиннан шулай ук көмеш медаль алып кайтты. Сноубордчы Виктор Вайлд исә Олимпиадада бронза иясе булып танылды. Бу спортчыларның барысы да Татарстанның дәүләт бүләкләренә ия булды. Евгения Тарасовага, мәсәлән, «Дуслык» ордены тапшырдылар. Калган спортчылар исә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медаленә ия булды. Бүләкләнүчеләр арасында Евгения Тарасова белән бергә чыгыш ясаучы Владимир Морозов, аларның тренерлары Максим Траньков, якташыбыз Камилә Вәлиеваның остазы Этери Тутберидзе да бар. Морозов белән Траньков Казан Кремлендәге очрашуда да катнашты. «Сез – башка төбәкләр өчен үрнәк. Алга таба Россия спортына ярдәм итүегезне сорыйм. Сөенечебез көмеш һәм бронза белән генә чикләнмәсен. Киләсе Олимпия уеннарында бирегә бары алтын гына булсын», – диде тантанага түбәтәй киеп килгән Максим Траньков.

# ҮЗЕБЕЗДӘ БАР

**Дәүләт программалары туктамас, сәнәгать тә эшсез тормас. Хөкүмәт йортында, ил-көндәге вакыйгаларга карамастан, тормышның үз көенә дәвам итүен искә төшерделәр. Икътисад югалтулары турында фаразлап утыру да урынсыз, диделәр.**

Һәрби вакыйгалар, санкцияләр дәүләт программаларына киртә булмаячак. Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова әйтүенчә, мондый куркыныч юк. «Хөкүмәт бу җәһәттән көн дә эшли, үз тармагы өчен җавап биргән министрлар белән очраша», – диде ул.

Сәнәгать тә хәзер импортны алмаштыру, кризиска каршы чаралар оештыру юнәлешен алачак. Бу уңайдан Лилия Галимова:

– «Макдоналдс», башка чит ил компанияләре турында гына уйларга кирәкми. Безнең үз сәнәгать мөмкинлекләребез дә җитәрлек. Әйтик, КамАЗ, авиатөзелеш өлкәсе. Хәзер төп максат – кризиска каршы тору эшен көйләп җибәрү, җитештерүчәнлек үсешен дәвам итү өчен импортны алыштыру, – диде.

Кремль вәкиле Татарстан кичерәчәк икътисади зыян күләмен санамаска киңәш итте. Россия базарыннан киткән халыкара компанияләр үзләре дә зыян күрәчәк.

Лилия Галимова республикадагы төзелеш эшләрендә катнашучы мигрантларның Татарстаннан күпләп китү мәсьәләсен дә шәрехләде.

– Мондый шартларда ике ел эшлибез инде. Пандемия чорында мигрантлар китү сизелде. Димәк, төзелеш тармагын эшче куллар белән тәэмин итү өчен өстәмә карарлар кабул ителер, башка юларын эзләрбез, – диде ул.

Сүз уңаеннан, Лилия Галимова әйтүенчә, республикада эшсезлек чәчәк атар дигән куркыныч юк.

– Компанияләрдән хезмәткәрләр җитмәү турында нинди дә булса гаризалар юк. Белгәнегезчә, компанияләр эшчәнлеген туктатып тору, әмма үз хезмәткәрләре өчен хезмәт хакын саклау турында игълан итә. Бу мәсьәлә – тармак министрлыгы контролендә. Вакансияләр саны да җитәрлек, – диде ул.

Татарстан Президентының эшлекле сәфәрләренә килгәндә, киләсе атнада аны Мәскәүдә көтәләр. Лилия Галимова әйтүенчә, башкалада тантаналы шартларда Казанга Ислам хезмәттәшлек оешмасының Яшьләр башкаласы исеме биреләчәк.

– Әлеге исем 1 елга бирелә. Бу дәвердә башкалада яшьләрнең сәяси, социаль, икътисади эшчәнлеген арттыру буенча эш алып барылачак, иң яхшы тәҗрибәләрне күрсәтү мөмкинлеге биреләчәк, – диде ул.

## Закон чыгаручылар чисталык турында сөйләшәчәк

**Киләсе атнада Казанда Идел буе федераль округы субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясенең 63 нче утырышында каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә реформа турында фикер алышачаклар.**

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Түбән Новгородта әлеге төбәкнең Закон чыгару Җыены рәисе, Идел буе федераль округы Закон чыгаручылар ассоциациясе координаторы Евгений Люлин белән әлеге чарага әзерлек турында сөйләште.

Казандагы очрашуда Идел буе федераль округы закон чыгаручылары төбәкләр тәҗрибәсен уртаклашырга, тикшерү барышында ачыкланган уртак проблемаларны хәл итү өчен федераль законнарны камилләштерү буенча берничә инициатива һәм тәкъдим белән чыгарга ниятли.

# КОМ БЕЛӘН КИРПЕЧ КЕНӘ ТҮГЕЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Быел Татарстанда 2 млн 755 мең квадрат метр торак төзергә җыеналар. Әлеге мәгълүматны Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин җиткерде.**

Былтыр бездә 3 млн квадрат метр торак сафка баскан. Идел буе федераль округында – беренче, Россия буенча алтынчы күрсәткеч бу.

Төзү генә түгел, булганны төзекләндерү өчен дә күп көч сарыф итмәкчеләр. Быел Татарстанда социаль-мәдәни тармак объектларын төзү һәм капиталь төзекләндерү, коммуналь инфраструктураны яңарту, торак төзелеше кысасында 44 республика программасы һәм илкүләм проектлар тормышка ашырылачак. Моның өчен 47 млрд сум чамасы акча тотарга ниятлиләр.

2022 елда республикада 760 күпфатирлы йортта капиталь төзекләндерү эшләре башкарылачак. Гомумән алганда, республикада тормышка ашырылучы төзелеш, төзекләндерү, капиталь ремонт программалары 3,5 меңнән артык объектка кагылачак.

Авыл халкы өчен дә күңелле хәбәр бар. Халыкны чиста су белән тәэмин итү өчен тотылачак акчаны ике тапкыр арттырганнар. Татарстан Президенты карары белән быел бу эш өчен 1,3 млрд сум акча тотарга җыеналар. Республиканың барлык район-авылларында су проблемасы хәл ителер дип өметләник.

Министр сүзләренә караганда, быел төзүчеләргә ял итәргә дә вакыт булмаячак. Ул яңа мәктәпләрне төзекләндерү, белем бирү йортларындагы ашханәләрне яңарту, балалар бакчаларын төзекләндерү, ФАПлар төзү, салынačак яшьләр үзәкләре, мәдәният йортлары хакында да сөйләде. Быел Яшел Үзән, Биектау, Саба, Чаллы, Әлмәттә – берәр мәктәп, Түбән Камада ике белем йорты ишекләрен ачачак. Казанда быел яңа мәктәп ачылмаячак, 2023–2024 елларда башкалада өч мәктәп төзеләчәк.

Ниятләр изге. Журналистлар исә министрдан бүгенге вазгыятьнең төзелеш тармагына ничек йогынты ясаячагы турында сорашты. Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, күпфатирлы йортлар төзелешендә кулланылган материалларның һәм җиһазларның 92 проценты үзебездә җитештерелә. Шул ук вакытта кайбер җиһазлар һәм аларга кирәк-яракларны табу кыенлаша башлаган. Өстәвенә бәя дә артып тора. Шулай да министр 2022 елга планлаштырылган төзелеш эшләрен башкарып чыгасыларын әйтте. Авырлык 2023 елда сизелергә мөмкин, ди ул.

– Без хәзерге вакытта импортны алыштыру юлларын эзлибез. Кытай белән сөйләшүләр бара. Бездә ут чыбыклары, чистарту корылмасы җиһазлары, җылылык насослары белән проблемалар булырга мөмкин, – ди ул.

Бәя арттырудан үзебезнең җитештерүчеләр дә читтә калмый икән. Моңа министр да аптыраган. Хәтта 100 процент бәясен түләп куйган чималларны да складта тотып, бирмичә торучы оешмалар бар, ди Марат Айзатуллин.

– Бездән тагын 30 процент күләмендә өстәмә акча сорыйлар. Бу дөрес түгел. Мөмкинлектән файдаланып, акча эшләп калмакчы булалар. Үзебездәге ком бәясен дә ике мәртәбә арттырып куйганнар. Әлегә бу намуссыз оешмаларда тикшерү эшләре бара, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# *Дәрестән тоз тәме килсен*

**Дәүләт Советында**

**Дәреслекләр дә бар, тик укырга теләүчеләр генә аз. Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында татар телен укыту мәсьәләсендә Казандагы «Бала-Сити» күптелле бакчалар челтәре директоры, депутат Альбина Насыйрова әнә шулай диде. Утырышта дәреслекләрне федераль исемлеккә кертү, туган телләрне укыту хакында сөйләштеләр.**

– Мин башкалабызның Вахитов районындагы берничә мәктәптә булдым. Меңләгән укучы белем алган уку йортлары бу. Андагы татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәчеләр белән сөйләштем. Китаплар белән проблема юк, һәр балага җитә, диделәр. Укытучылар да бар. 48 төркемдә татар телен – чит, бары ике төркемдә генә туган тел буларак сайлаганнар. Соңгыларында 5–10 бала утыра. «Ни өчен татар гаиләләре балаларын татар төркемнәренә бирми?» – дип кызыксынгач, монда уку җиңел, дип аңлаттылар, – диде Альбина Насыйрова.

«Бала-Сити» мәктәбендә исә 315 бала белем ала. Алар арасында төрле милләт балалары бар. 115 бала татар телен – туган тел, 200е чит тел буларак өйрәнә. «Башка милләттән булган малай, минем татар балалары белән бергә көчле төркемдә укыйсым килә, ди. Ни өчен чит илләрдән килгән гаиләләргә татар теле кирәк, ә татарларга юк? Без татар төркемнәрендә татар телен «Сәлам» дәреслекләре буенча укытабыз, укытучылар бик мактый. Укытучылар нинди программа бирсәләр дә, шуның белән эшләргә әзер. Тик атнага ике сәгать татар телен укытып кына телгән нәтиҗәләргә ирешә алмыйбыз, диләр. Без татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен клублар оештырдык. Мәктәпләрдә дә бу эшне башлап җибәрергә кирәк дип уйлыйм. Биш ел элек бастырылган дәреслекләр белән чагыштырсак, методика да, китапларның бизәлеше дә бик яхшы. Бары бер теләк: дәрескә яратып йөрсеннәр иде», – ди Альбина Насыйрова.

Башкаладагы «Адымнар» күптелле белем бирү мәктәбе директоры Айдар Шәмсетдинов әйтүенчә, уку йортында барлыгы 3600дән артык бала (шуның 1100е – саф татар төркемендә) белем ала. Бондаренко урамында урнашкан татар корпусында туган телне атнага бишәр сәгать укыйлар.

– Яңартылган федераль стандартлар буенча кабул итү көн үзәгендә торачак. Чөнки сәгатьләр саны кими. Бу безне бик борчый. Төрле дәреслекләрдән файдаланабыз. Соңгы вакытта мәктәпкә яңа татар буын балалары арасында туган телләреннән читләшүчеләр килә. Аларга татарчаны ныклап өйрәтеп булмый, чөнки аңламыйлар. Шуңа күрә КФУ белән берлектә өр-яңа «Адымнар» дигән татар теле дәреслеге эшлибез. Шуның аша туган телне атнага биш сәгать өйрәтеп, 7 нче сыйныфтан әдәбиятны укытып, балаларны татарлаштыруга ирешербез дип уйлыйм, – диде Айдар Шәмсетдинов.

Мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин туган телләр буенча дәреслекләр эшләү, аларны федераль исемлеккә кертү проблемалары хакында сөйләде. «Россиядә мәгариф турында»гы Закон нигезендә туган телне әти-әниләр сайлый. Бүген 89 дәреслек федераль исемлеккә кертелгән. Хәзер сүз яңа басмаларны кертү турында бара. Туган телләрне укыту буенча барлыгы 69 дәреслекне федераль исемлеккә тәкъдим иттек», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов милли мәгарифнең беркайчан да җиңел булмавын ассызыклады, депутатларның утырышка җитди әзерләнүен билгеләп үтте.

– Дәреслекләрне әзерләгәндә, бик югары осталыкка ия булган укытучылар, мәктәп коллективлары белән киңәшләшеп эшләргә кирәк. Күңелне дәресләр санынан бигрәк, әти-әниләрдә, балаларда туган телгә карата кызыксыну булмау борчый. Бу теманы күтәрәбез, әмма җавап таба алган юк. Күңелдәге рухи бушлыкны тутыру өчен нәрсә эшләргә? Бу сорауга җавап табарга булышсагыз иде. Биш-алты укыту программасы бар икән, ким дигәндә, ике-өчесенә туган телләр кертелгән. Әгәр җитәкче татар җанлы булмаса, ул үзенә җиңелрәк, туган тел булмаган программаны сайлый. Әлбәттә, әти-әниләр битараф булган очракта, моңа берәү дә каршы килми. Милли мәгарифне республикада саклагыра телибез икән, без урыннарда милли җанлырак җитәкчеләр турында уйларга тиеш. Бу мәсьәлә – көн үзәгендә. Атнага дүрт сәгать укытып та, аннан тоз тәме килмәскә, шул ук вакытта ике сәгать белән дә укытучы үзен һәм телне яраттыра алырга мөмкин, – диде Марат Әхмәтов.

Сәрия МИФТАХОВА

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

# Сагыну

Онычым Кәрим әнисе белән, дөнья күрергә дигәндәй, Гарәп Әмирлекләренә – Дубайга киткән иде. Бик сагынабыз үзен. «Баламның баласы балдан татлы» дигән гыйбарә телдән-телгә, буыннан-буынга күчеп килсә дә, сагынып карамаган кеше аның асыл мәгънәсенә төшенеп җитә алмаячак.

Ярый инде, без – өлкән кешеләр. Ә менә җиде яшьлек онычыбыз ни өчен безнең илне сагына икән? Ул бит әле «туган җир», «ватан», «туган нигез» дигән төшенчәләрне бөтенләй аңламый. Әмма соңгы вакытларда әнисенә: «В Россию хочу!» – дип әйткәли башлаган. Юкса киткәннәренә әле ай да юк. «В Россию» дип кенә калмый, «Казанга, Дубравная урамына» дип тә өсти икән. Дубравная, ягъни «Имәнлек» – без яшәгән урам инде.

Бер-ике мәртәбә дәү әнисе белән видеоэлемтә аша сөйләшеп тә алганнар. Сабыем: «Дәү әти һаман шаяртамы?» – дип тә сораша икән. Әле: «Суыткыч өстендәге тузанны сөртәсезме? Минем зоопарк ни хәлдә?» – дип тә сорый икән. Пластилиннан төрле җәнлекләр әвәләп, зоопарк ясаган иде ул. Сагыну хисләрен сабый күңеле белән әнә шул, бер караганда, вак-төяк сораулар аша сиздерә Кәрим.

Дубай – ял итү өчен җәннәт кебек. Анда кояшлы, җылы, онычым көн саен су коена. Рәхәтләнеп тик кенә ятасы иде дә бит, әмма сабый күңеле тынычлык тапмый, үзенчә бәргәләнә. Туган җир, туган нигезне сагыну, күрәсең, һәр тереклек иясенә геннар аша киләдер. Җылы якка киткән кошларны гына кара син! Кайсының чит җирләрдә төпләнеп калганы бар? Без әле «матур булса да торган җир, сагындыра туган ил» дип тә җырлыйбыз. Әлбәттә инде, күчмә кошлар бу җырны белми, әмма адашмыйча нәкъ менә туган җирләренә, хәтта үз кулларына, үз бакчаларына, үз ояларына кайталар. Һәр авылның үз сыерчыгы, үз сандугачы, үз турганы бар. Туган авылым Субаш-Атыга да чит кошлар кайтмыйдыр дип уйлыйм, барысы да бездән киткәннәр.

Әтием Солтан һәр язны бакчага чыгып: «Әнә безнең сыерчыклар кайткан», – дип әйтә торган иде. Бала чагымда мин аның «безнең сыерчыклар» дип әйтүенә игътибар итмәдем. Әллә кайларга киткән кошлар ничек итеп нәкъ менә Субаш-Атыга, безнең лапас түбәсенә, өй кыегына беркетелгән ояларына кайта алсын ди!

Инде соңрак, мәктәптә укый башлагач, укытучы апабыз кошларның үз-үзен тотышлары турында гаҗәп кызык нәрсәләр сөйләп, безне шаккатырды. Кайталар икән шул канатлы дусларыбыз туган җирләренә. Алай гына да түгел, Субаш-Аты сыерчыгы, мәсәлән, Наласага, йә Утар-Атыга түгел, ә безгә, үсә төшкәч үзем ясаган ояларга кайта икән.

Озакламый кошлар кебек әйләнеп, онычым Кәрим дә кайтыр. Күптән түгел тавышын яздырып тагын бер хәбәр җибәрде. Дөньяларның бик үк тыныч булмавын каян белгәндер җиде яшьлек сабый. «Украина Россиягә һөҗүм итмәдеме?» – дип язган. Аңа ничек җавап бирергә дә аптырадым. «Монда бар да тыныч, улым. Дәү әниең көн дә чаңгы шуа, мин эшкә йөрим», – дип язган булдым инде. Ә ул тагын хәбәр җибәрде. «Чаңгы шуарга кар бармы әле, фотога төшереп җибәрегез!» – дигән. Аның бар хәбәрләрен сагынуга юрыйм һәм дәрес тә эшлимдер. Минем «бу заманда җүнле кеше чит илгә китә» дигән сүзләрне дә ишеткәнем бар. Моны, гадәттә, читкә чыгып караманнар әйтә кебек. Ә менә минем онычым туган илен сагына, дәү әнисе әйтүенчә, шунда ял итүче бер дусты белән Россия гимнын да шыңшып йөриләр икән. Аның әтисе – улым Булат та: «Чит ил бер күреп кайту өчен генә кирәк», – дип еш әйткәли. Алма агачыннан ерак төшмәгән, ахрысы.

Кәрим әле бер хәбәрендә минем туган авылымны да искә төшергән: «Дәү әти, быел да кайтабызмы?» – дигән. Кайтмый ни инде, улым! Карлар бетеп, җирләр кибүгә, алып кайтам мин сине, Аллаһ боерса.

Кызык хәл: улым хәзер чит шәһәрдә яшәсә дә, җәй көне Субаш-Атыга кайтмый калмый. Бер уйлаганда, авылда инде беркемебез дә юк, әти нигезе буш. Әмма Булатның балачагы авылда узды, без аны, татарчасын да онытмасын дип, һәр елны җәйге каникул вакытында авылга кайтара идек. Бүген әнә шул балачак эзләре буйлап йөрисе килә Булатның. Шулай итеп авылны сагыну хисләрен баса, күңелен тынычландыра ул. Бу хисләр, күрәсең, геннар буенча аның улына да күчкән. Үзебез нинди – балаларыбыз шундый инде.

Кәрим улым, сине бик сагындык, тизрәк кайт инде, яме! Туган илгә, торган җиргә җитми инде.

# ҮЗЕБЕЗНЕКЕН ҮЗЕБЕЗ АШАСАК, КӨЧЕБЕЗ АРТЫРМЫ?

Соңгы көннәрдә вакыйгалар баш әйләнгеч тизлектә үзгәрә. Бездә хәлләр таудан чабып төшкән кебек инде, бу хакта сөйләшеп тә тормыйбыз. Көнбатышта да оптимизмга сәбәпләр юк. Италиянең элекке Премьер-министры: «Санкцияләрнең Россиягә каршы гына түгел, безгә каршы да кертелүен мин бензин колонкасы янына туктагач кына аңладым», – дип белдерде. Әйе, Көнбатышның Россиягә каршы башлаган махсус икътисад операциясе аларның үзләренә дә бик каты суга һәм алар моны яшермиләр. Байден, мәсәлән, Россия нефтен сатып алуга тыю керткәндә, үзләрендә бензин бәясенең күтәреләчәген аңлавын әйтте. Россиядә исә әлегә мотор ягулыгына бәяләр тотрыклы, алар да күтәрелсә, кушаяклап сикергән инфляцияне бөтенләй авызлыклап булмаячак...

Меңнәр һәм йөз меңнәр эшсез калып, иртәгесе көнгә сагаеп караган бу вакытта күңелдә сорау туа: «Нишләргә?» «Импортны алыштырырга, үзебезнең товарларны җитештерүгә күчәргә», – дигән тавышлар 2014 елдан кайтаваз булып яңгырый. Күрәбез, без әле 8 ел эчендә глобаль базарларга бәйлелектән аз гына да котыла алмаганбыз. Ә бит зур максатлар куелган иде. Һәрбер министрлыкта, һәрбер сәнәгать предприятиесендә импортны алыштыру планнары-программалары төзелгән, бихисап отчетлар язылган иде. Әмма...

Пессимистлар булмыйк, уңышлар да юк түгел ул үзе. Соңгы елларда Россия элекке ашлык сатып алучы илдән аны экспортлаучы лидерларның берсенә әверелде. Үткән ел чимал булмаган экспорт күләме рекордлы дәрәҗәгә ирешкән. Теләсәң, ирешелгәннәрне санарга була. Вәләкин... Вазгыятькә аек акыл белән карыйк: уңышларга чит илләр белән элемтәне өзеп түгел, үзара хезмәттәшлек итеп ирештек. Бу дөньяда гы бер генә бренд та, дөнья базарын яулап алган бер генә компания дә үзе җитештергәннәр белән генә уңышка ирешә алмый. «Тойота» да, «Ниссан» да, «Фольксваген» да, башка бик күп җитештерүчеләр дә чит илләрдән алган комплектлаучы детальләрдән җыялар үз технологик продуктларын. Ни өчен шулай эшлиләр? Сорауга җавап итеп, өй салу кебек гади генә мисалны сурәтләп күрсәтик әйдә.

Бары тик үземнеке генә булган өй салам дип хыялланыйк. Бар материаллар, бар нәрсәне үзем генә җитештерәм дип максат куйыйк. Иң башта безгә үзебезнеке булган җиргә төзелешкә яраклы агач утыртырга һәм аның өй салырлык яшькә җитүен йөз-йөз илле еллар тирәсе көтәргә туры киләчәк. Ул арада без кадак җитештерүне, цемент заводын көйли тора алабыз, кирпеч сугуны җайлыйбыз. Әмма кадак җитештерүгә күчкәнче, металл рудасы табып, мартен миче кабызырга туры киләчәк. Һәм без мең ел эчендә дә максатыбызга ирешмәячәкбез. Нииндидер бер технологик могҗизага юлыгып боларны оештыра алсак та, безнең өйнең бәясе триллион сумнарга төшәчәк. Бәяне киметү өчен, безгә кадакны, кирпечне, агач материалларын һәм башкаларны сатып алучыларны күпләп табарга кирәк булачак. Шуңа өстәп берничә йөз мең әзер өй дә сатарга туры килер. Шул очракта гына өйнең үзкыйммәтен киметеп булыр иде.

Хәзер бу мисалны Россия масштабына күчерик. Нииндидер бер үзебезнең детальләрдән генә торган яңа технологик продукт җитештерә башладык, ди. Тышкы базарларга чыга алмасак, ул гаҗәп дәрәҗәдә кыйммәт булачак. Глобаль капитализмның бердәнбер уңышлы ягы – товарны миллионлап җитештерү нәтиҗәсендә аның бәясен түбән тоту. Шуңа күрә барлык брендлар да комплектлаучы детальләрне читтән алып, яңа продукт тудырырга һәм аның белән дөньяны яулап алырга омтыла. Шуңа күрә Россия компанияләрен чит ил комплектлаучы детальләре һәм материаллары белән эшләүдә гаепләргә ярамый. Без хәтта ашлыкны да күп очракта чит ил тракторларына импорт чәчкечләр тагып чәчәбез һәм чит ил комбайннары белән җыеп алабыз... Шулай арзангарак чыга ул. Уңышка ирешергә теләсәк, безгә башка илләр белән котылгысыз рәвештә хезмәттәшлек итәргә туры киләчәк. Кытай, Һиндстан, Төркия кебек гигантлар әлегә безгә артлары белән борылмады. Зур потенциал бу. Әмма алар безне файдаланырга, үзләреннән бәйлелеккә тотарга тырышачак. Башка базарларның ябык булуы аларга шундый мөмкинлек бирәчәк. Алар хәтта бездән чималны арзанга алып, Көнбатышка кыйммәткәрәк сатарга омтылачак.



worldskills2019.com

Төркия бүген үк Россия газын реэкспортлый, мәсәлән. Табыш ала. Бу хәлдән чыгу өчен Россиягә Көнбатыш белән сөйләшүләр өстәле янына утырырга туры киләчәк. Әлегә безгә санкция кертүчеләр чикләүләрне туктатырга каршы түгел. Нәрсә таләп итүләрен аңлыйсыздыр инде. Барлык конфликтлар да сөйләшүләр өстәле янында төгәлләнә. Менә шул өстәл янында никадәр тиз килешүгә ирешелсә, без үзебезнекен җитештерүгә шулкадәр тизрәк күчә алачакбыз. Океан артыннан Кытайга да басым ясыйлар хәзер, Россия белән элемтәләрне өзәргә өндиләр. Моңа юл куярга ярамый.

Кечкенә генә нәтиҗә ясыйк әле әйтелгәннәрдән: үзебезнекен җитештерә башлау өчен безгә чит илләр белән конфронтациягә керергә түгел, хезмәттәшлек итәргә кирәк.

Бу юлларның авторы кризисларда сакал агартты. Нинди генә кризислар кичмәдек без. 1998 елда доллар курсы өч-дүрт, хәтта биш тапкыр күтәрелде. 6 сумлык долларның 30 сумга йөргән мизгелләре булды, ахырдан шул ноктада ныгыды да инде ул. Әмма ул елда әле Россия дөнья базары белән буй һәм аркау җепләрен аралаштырып бетермәгән, иномаркаларда мафиозниклар гына йөри, смартфоннар бөтенләй юк иде. Совет чоры сәнәгате дә җимерелеп бетмәгән иде. Шул сәбәпле, сыйфатсызрак булса да, үз продукциябезне җитештерүне җайга салу кыен булмады. Примаков Хөкүмәте сәнәгатьне берникадәр җанландырып, массакүләм эшсезлектән котыла алды. Тагын бер мөһим як бар: беркем дә безгә каршы санкцияләр кертмәгән иде. Бик авыр еллар иде ул: кесә төпләре такыр, хезмәт хакларын алты айга-бер елга соңга калып бирәләр. Шулай да без аларны кичтек. Хәзер вазгыять бөтенләй башкача. Бик кирәкле беренче кулланы товарлары белән үзебезне тәэмин итә алырбыз, әлбәттә. Бик кыйммәт булыр инде алары да.

Бу юлларның авторы якын көннәргә оптимистик фараз бирә алмый. Безнең барлык оптимизмыбыз бүгеннең иртәгесе көннән яхшырак булуын аңлауда гына. Март апрельгә караганда яхшырак, апрель – майга караганда. Бу хәлгә шатлану – Булгаковның Шариковы фәлсәфәсе инде ул. Әмма моны аңлау безгә авырлыкларны җиңелрәк кабул итәргә булыша ала. Никадәр генә катлаулы булмасын, бу вазгыятьтә романтика күрәм мин үзем. Тоннельнең теге башында яктылык бар, әмма безгә күренми генә. Глобаль капитализм дигән поезд зур тизлектә тоннельгә кереп бара, кергән саен караңгырак булачак. Тоннельнең уртасына җиткәнче шулай булачак. Менә шул «урта»да тупикка килеп терәлмәс өчен нык тырышырга туры киләчәк безгә. Шуны узсак, яктылык күрә башлаячакбыз.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

# ЧИКЛӘНМӘГӘН МӨМКИНЛЕКЛӘР

## САНКЦИЯЛӘРНЕҢ ФАЙДАСЫН ЭЗЛӘРГӘ КИРӘК, ДИ БЕЛГЕЧЛӘР

**Дөнья икътисадында кризис – табигый күренеш. Хәзерге вакытта ил бизнесына үзенең иң асыл сыйфатларын – чыдамлыгын һәм яңа шартларга тиз арада җайлаша алуын күрсәтер чак җитте. Россиягә каршы бер-бер артлы кертелгән санкцияләрдән уңай сабак алырга мөмкинме? Вазгыятьне үз файдабызга борып булырмы?**

### Дегет мичкәсендә бал да бар

Тәмәкедән башлап валютага кадәр. Чит ил компанияләре Россиядә көнкүрештә кулланыла торган кирәк-яракларны, азык-төлек, тәмәке, косметика, техника, автомобиль һәм башкаларны җитештерү-сату-куллануны тыйды. Әлбәттә, «нишләрбез» дип аптыраучылар да, шул ук вакытта мөмкинлектән файдаланып, үзебезнекен булдырырбыз дип илһамланучылар да табылды. Ятып калганчы, атып калырга кулайрак түгелме? Белгечләр дә «Тирә-юнь тотрыксызланып, нигез югалганда, яңа урында нәрсә тудырып була?» дигән сорауга җавап уйларга киңәш итә.

Бер мичкә дегеттә бер кашык бал табылмый калмас. **Финанс консультанты, инвестицияләр һәм шәхси капитал белән идарә итү өлкәсендә белгеч Игорь Файнман** шул фикердә.

– Әлбәттә, хәзерге вазгыять бик катлаулы, кешенең баш мие дә көн саен матбугат чараларыннан килгән негативны электереп алырга тора. Тик һәр нәрсәнең уңай якларын да эзләргә кирәк. Алар юк түгел, – ди ул. – Бердән, Россиядән акча чыгару күпкә катлауланды. Димәк, капитал ил эчендә тупланачак. Бу инде үсешнең тизрәк баруына китерәчәк, башкача мөмкин түгел. Бизнес, физик затларга яңа ташламалардан файдалану мөмкинлеге биреләчәк. Дивидендлар (акционерлык оешмасының аның катнашучылары арасында бүленә торган табышының бер өлеше) да бар бит әле. Экспорт компанияләре быелтыр зур гына табыш алды. «Дивиденд портфеле»нә ия булган кешеләргә аннан файдалану мөмкин, – ди ул. – Хәзерге вазгыятьтә виртуаль дөньядагы тискәре яңалыклар үзәгеннән чынбарлыкка, элеккеге тормышка кайту бик мөһим. Моны эшләү авыр, әмма эшләргә кирәк. Нинди юнәлештә сез көчле, шуларны кулланырга. Ничек кенә сәер яңгырамасын, әмма хәзер үсеш өчен бер дигән мөмкинлек барлыкка килә, һәм аны кулдан ычкындырмаска иде.

**«Набалансе» бухгалтерия фирмасы җитәкчесе Гаяне Мөхәммәтҗанова** да авыр шартларда яңа мөмкинлекләр ачылачак дип саный.

– Санкцияләр кертү төрле юнәлешләр буенча бизнес алып бару икътисадында чагылыш тапты. Теләсә кайсы эшкуарлык тармагы хәзерге вазгыятьнең бөтен «матур»лыгын үз өстендә тойды. Җирле бизнес өчен чимал, җиһазлар, комплектлау әйберләре өчен бәяләр артуны аерууча сиздә. Кредит алу мөмкинлеген киметү дә эшлекле мөнәсәбәтләр алып баруга йогынты ясады. Шулай да, авыр шартларда да яңа мөмкинлекләр табарга була, – ди белгеч. – Кризис чорында эшне идарә итү исәп-хисабын анализлаудан башларга кирәк. Дөрес анализ алга таба финанс планын аңлы рәвештә төзергә ярдәм итәчәк. Мәсәлән, яңа уңай шартлар тәкъдим итәрдәй контрагентлар эзләргә мөмкин. Санкцияләр импортка алмаш табу мөмкинлекләрен киңәйтә. Кертелгән чикләүләрнең тагын бер өстенлеге – көндәшлекнең кимүе. Кулай вакытта эш иткән чакта, икътисад базарында ышанычлы урынны алып калырга мөмкин. Шул рәвешле клиент һәм сатып алучыларның ышанычын яуларга, озак вакытка исәпләнгән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырырга. Иң мөһиме – үз көчмөмкинлекләреңне ялгышмый исәпләргә һәм эш итәргә, – дип аңлатты белгеч.

### Эшмәкәрләр кәефе

**«Таймас-груп», «Трейд-ин центр», «Итил» компанияләре генераль директоры, эшмәкәр Динар Минәхмәтов** дистә елдан артык бизнес белән шөгыльләнә. Кризисның 2008, 2014 елдагыларын да кичкән ул. Гомумән, чикле тормыш ил өчен дә яңалык түгел инде. Команда бердәмлеге, рух ныклыгы һәм вакытында кабул ителгән карарлар бәрабәренә кыенлыкларны узарга була, ди эшмәкәр. Барысы да вакытка һәм Хөкүмәт дәрәҗәсендәге ярдәмгә бәйле.

– Кече, урта бизнеска һәм халыкка дәүләт ярдәме булсын иде һәм ул булыр дип өметләнәм. Әйтик, ташламалы кредит, түләүне кичектереп торулар. Эшмәкәр үз көче белән генә бу шартларны җиңеп чыга алмас. Кыска аралыкта караганда, вазгыять катлаулы. Киләчәккә карасак, бизнес өчен яңа мөмкинлекләр ачыласын фаразлап була. Алга таба үсеш булсын өчен халыкның керем дәрәҗәсе төшмәве мөһим, – дип саный Динар Минәхмәтов. – Бүген импортны алмаштыру буенча чаралар гамәлгә кертелә, хөкүмәт фәнни һәм технологик эшләнмәләр белән шөгыльләнүче компанияләр өчен салым режимын җиңеләйтә, шулай ук капиталлар амнистиясе көтелә. Бу катлаулы чорда Татарстан Хөкүмәте халыкның һәм бизнесның барлык катламнарына ярдәм итү механизмнарын эшләү буенча актив эш алып бара.

**Яшь фермер, эшмәкәр Рушан Сайранов**, хәләл стандартларга туры китереп, ит өчен тавык үрчетә. Чикләүләр җирле эшкуарларның продукциясенә игътибарны арттырыр, дип өметләнә ул.

– Санкцияләр еш кына җирле сәнәгать, җитештерүчәнлекне арттыруга юл ача. Яхшы этәргеч булыр дип саныйм. Үзебезнеке дә кайчан да булса бер үсеш алырга тиештер бит инде. Тагын бер сорау: читтән кертелгәне тулысынча бетәрме икән соң? Алар да башка илләр аша кертү җаен карарга мөмкин. Бу очракта сатып аласы продукция тагын да кыйммәткә төшмәгәе. Икътисади яктан караганда, чикләүләр керткән илләргә Россия кадәр Россия базарын югалту бер дә кулай түгел. Эшмәкәр буларак, безнең өчен позитив үзгәрешләр буласына өметләнәм, – ди белгеч.

Бу арада Казан эшмәкәре, **«Кыстыбый-food» милли фастфуд челтәренә нигез салучы Азат Нәҗметдиновка** социаль челтәрләрдә халык арасында популярлык казанган зур фастфуд челтәрләре ябылу турында хәбәрне аеруча күпләп җибәргәннәр. Янәсе, үзебезнекеләргә юл ачыла, тәвәккәлләргә вакыт. Эшмәкәр исә әлегә ашыкмый. Барысы да бер көймәдә йөзә бит чөнки.

tatarstan.ru

> **Киңәш**
>
> Хезмәт хакы күләменең зурлыгы белән артык мактана алмаган, җыелган маясы, өстәмә керем чыганагы булмаган кешеләргә кризис шартларында нишләргә? Билгеле, таякның каты башы аларга ныграк сугачак. Андыйларга берничә киңәш.
>
> 1. Үз чыгымнарыгызны көйләргә тырышыгыз. Әйтик, мәҗбүри (азык-төлек, торак-коммуналь хуҗалык өчен түләү, дару) һәм мәҗбүри булмаган (уйланылмаган сатып алулар, күңел ачу, хобби) чыгымнарга бүлегез.
> 2. Ашыгыч ихтыяҗ юк икән, кыйммәтле товарлар сатып алмагыз.
> 3. Кибетләрдә махсус ташламалар, акцияләр булмый тормый. Күзәтеп барыгыз.
> 4. Мөмкинлек булса, кредитларны вакытыннан алда түләп куегыз.
> 5. Аз-азлап булса да, «финанс мендәре»н булдыру турында кайгыртыгыз, мая туплагыз.
> 6. Нинди дә булса ташлама каралган гражданнар категориясенә керәсез икән, кичекмәстән бу категория өчен билгеләнгән социаль ярдәм чаралары турында белешегез.

– Таякның ике башы бар. Әлбәттә, бер яктан, безнең өчен зур базар ачыла, кешеләрне үз продукциябез, концепциябез белән таныштыру мөмкинлеге арта. Безнең сату 20–30 процентка артыр дип уйлыйм. Икенче яктан караганда, ябылачак фастфуд челтәрләрендә әллә ничә мең кеше хезмәт куя. Күбесе логистика, хезмәт күрсәтү, продукция белән тәэмин итү тармакларында эшли. Эшсез калулары аларга зыянга булачак, бу инде халыкның кереме кимүенә китерәчәк. Хезмәт базарында эш эзләүче яңа белгечләр барлыкка киләчәк, бу – безнең командабы көчле хезмәткәрләр белән тулыландыру өчен мөмкинлек, – ди Азат.

Эшмәкәр әйтүенчә пандемиягә кадәр чордагы икътисадка кайту мөмкин түгел инде. Шуңа да яңа шартларга җайлашу юлларын эзләргә кирәк.

– Дөресен әйткәндә, «Алга таба ни булыр?» дигән сорауны ешрак ишетәбез һәм моңа төгәл җавап тапканыбыз да юк. Алга фаразлау кыен. Әлбәттә, ниндидер стратегия буенча эш итәбез. Билгеле, бу чикләүләр бизнеска бәрәчәк. Тик теләсә кайсы кризистан кызыклы мөмкинлекләр табарга була. Сынатмабыз дип уйлыйм, – ди Азат Нәҗметдинов. – Аз-азлап өч-дүрт мәртәбә продукциягә бәяне арттырдык. Ансыз булмас та иде. Барлык хезмәтләрнең үзбәясе арта бит. Бу – мәҗбүри гамәл.

### Медальнең икенче ягы

Ничек кенә булмасын, җиңел булмаячак. Казанда шәхси кием-салым брендын булдырган әңгәмәдәшебез дә шундыйлардан.

– Коронавирус пандемиясе чорында бик начар шартларда эшләдек. Проектны саклап кала алдык анысы. Хәзер дә кыен. Илебездә сыйфатлы чимал юк. Бар чимал долларда сатып алына. Хәзер бәя ике мәртәбә үсте. Әйтик, 2015 елда безнең күлмәк 5500 сум тора иде. Халык күпләп, яратып сатып алды. Ул чакта доллар 55 сум булгандыр. Хәзер 5500 сумлык күлмәкне дә «кыйбат» диләр. Гәрчә доллар бәясе күптән 100дән артты. Безнең товарның үзбәясе артты, ә сату кимеде. Җитештергән кешенең хәле кыен. Кризиска кергәнче үк, җитештерүчеләрне алдан әзерләргә кирәк, чимал белән тәэмин итәрдәй фабрикалар булдырырга, мәсәлән. Суда йөзә белмәгән баланы диңгезгә болгап аткан кебек инде. Йә үлә, йә исән кала, әмма мәңгелек куркуы булачак, – дип сөйләде ул исемен күрсәтмәү шарты белән. – Эшмәкәр ярдәм көтеп утырырлык зат булса, бу эшкә алынмый да. Бу – ирекле карарыбыз. Монда инде зарланып булмый, чөнки урынсыз.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

# АШ БУЛСЫН!

## АЗЫК-ТӨЛЕК ЗАПАСЫ ҖИТӘРЛЕК

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Бәяләр**

**«АШАН»**
*(килограммнарда)*
•Шикәр комы – 58 сум 49 тиен.
•Тоз («Илецкая») – 11 сум 99 тиен.
•Он («Макфа») – 59 сум 90 тиен.
•Карабодай («Макфа»), 800 граммлы кап – 109 сум 90 тиен.
•Гадәти карабодай – 79 сум 88 тиен.
•Көнбагыш мае («Злато») – 119 сум 90 тиен.

**«АГАТ»** *(карта белән һәм картасыз алган очракта аерыла)*
•Рафинад шикәр («Восточная столица») – картасыз – 100 сум 31 тиен, карта белән – 91 сум 20 тиен.
•«Макфа» оны (2 кг) – карта белән – 103 сум 85 тиен, картасыз – 119 сум 01 тиен.
•Шикәр комы («Агросила») – картасыз – 87 сум 87 тиен, карта белән – 75 сум 95 тиен.
•Илецк тозы – картасыз – 13 сум 12 тиен, карта белән – 11 сум 93 тиен.
•Карабодай («Макфа») – картасыз – 117 сум 18 тиен, карта белән – 106 сум 55 тиеннән башлап.

**«ПЯТЕРОЧКА»**
•Көнбагыш мае («Злато») – 109 сум 99 тиен.
•«Макфа» оны (1 кг) – 69 сум 99 тиен.
•Шикәр комы – 56 сум.

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

### «Моңа әзер түгел идек»

Азык-төлек бәяләрен һәм аларның барлыгын-юклыгын без кибетләргә барып ачыкладык. Иң элек Җиңү проспектында урнашкан зур кибетләрнең берсе булган «Ашан»га сугылдык. Гомумән алганда, кибеттә халык күп дип әйтеп булмый. Тик булганнарының барысы да диярлек шикәр комы, он, тоз, көнбагыш мае сатыла торган рәтләр тирәсендә бөтерелә. Шикәрнекеннән кала, киштәләр тулы. Без барганда исә шикәрнең «Золотой казан» каплы рафинад төре генә калган иде. Килограммы – 91 сум 10 тиен.

– Сез бу вакытта шикәр таба алмассыз инде, төшкә кадәр алып бетерәләр, – диде кибеттәге менеджер. – Бу берничә көндәге халыкны күрсәгез... Котырып алдылар. Әле дә бар шикәр. Көн саен иртән киштәләрне тутырып куябыз, тик берничә сәгать эчендә алып бетерәләр. Бөтен кешегә дә җитсен өчен, чикләүләр кертергә карар кылдылар.

Бүгенгә «Ашан» кибетендә бер кулга 10 кг шикәр комы, 10 шешә көнбагыш мае, 2 килолы биш кап он һәм өч кап тоз бирәләр.

Берничә ир-ат һәм хатын-кызның арбаларына кап-кап шикәр комы тутырганын күреп: «Сез бу кадәр шикәрне нигә аласыз соң?» – дип сорадык. «Арзанайган бит. 108 сум иде. 77 сум 90 тиенгә төшергәннәр. Булган чакта алып куйыйк, дибез», – дип җавап бирделәр.

Чираттагы тукталышыбыз Оренбург трактындагы «Агат» кибете булды. Биредә дә килограммы 70 сум тирәсендә сатылган арзанлы шикәр калмаган иде. Ә менә җитештерүчесе башка булган кыйммәтлерәк бәядәгесенә кытлык күрмәдек. Анысы 120 сум тора. Беренче чиратта мөһим булган башка төр азык-төлек барысы да җитәрлек иде. Биредәге кибет бөтенләй буш диярлек. Арба-арба товар төягән бер генә кешене дә күрмәдек.

– Ыгы-зыгы 2 мартта башланды. Бәйрәм һәм ял көннәрендә халык бик күп иде. Сишәмбегә кими башлады, – диде безгә кибет директоры Фәрхәд Ешмуратов. – Ярмалар һәм макаронны көненә 4 мең данә саттык. Гәрчә гадәти көннәрдә бу сан 500–700не тәшкил итә иде. Хезмәткәрләрне эшкә чакырып чыгарырга туры килде, чөнки кинәт күтәрелгән мондый халык агымына әзер түгел идек. Киштәләрне тутыра тордык, ул бушый барды. Складларда кытлык юк, шуңа күрә һәр нәрсә гадәти режимда эшләнде. Без әле тагын 400 оешма белән эшлибез. Аларга да товар ташыйбыз. Бу көннәрдә бар халыкның телендә булган шикәр проблемасы да юк бездә. Узган атнада зур фура килде. Әйе, шәп алалар, тик киштәләрне тутырырга өлгерәбез. Бер көн дә шикәргә кытлык булмады. Дөрес, арзанлырак бәядәгесен бик тиз алып бетерәләр. Мәсәлән, андый шикәр кичә бетте. Иртәгә тагын алып киләчәкләр. 70–80 сум тирәсе торган он, карабодай да тиз бетә.

Фәрхәд Ешмуратов әйтүенчә, әлегә иске запаслар булгач, бәяләрдә үзгәреш күзәтелмәгән. Көнкүреш товарларыннан исә бәдрәф кәгазе, памперс һәм шампунь күп сатылган.

– Әгәр алга таба да шундый ук ихтыяҗ булса, бу филиалда гына да ике атнага җитәрлек азык-төлек запасыбыз бар. Китереп торалар бит, кытлык аннан соң да булмас иде, – диде кибет директоры.

Кичкә таба арзанлы бәядән шикәр комын һәм карабодай ярмасын «Магнит», «Пятерочка» кибетләрендә дә тапмадык. Тик сатучылар әйтүенчә, әлеге төр товарларны китереп торалар.

– Бик тиз алып бетерәләр. 4 көн элек шикәрнең килограммын – 56 сумнан, онны 67 сумнан саттык. Әлегә китермәделәр. Бәлки бүген булыр, дип көтәбез, – диде «Магнит» кибете сатучысы.

«Пятерочка» кибетендә дә шундыйрак хәлләр күзәтелә. Монда бер кулга 3 кг гына шикәр бирәләр. Тик кичке якта анысы да калмаган иде.

– Шикәрне бу ыгы-зыгыга кадәр нинди бәядән саткан булсак, бүген дә шул бәядән җибәрдек. Бер килограммы 57 сум тора. Иртәгә иртән киштәләрне кабаттан тутырып куячакбыз, – диделәр.

Чыннан да, без кергән кибетләрдә арзанлы бәядән шикәр, карабодай, он табып булмады. Алары булмагач, халык кыйммәтлесен сатып ала, ләкин аңа карап, бер генә кибеттә дә кытлык бар, дигән сүз ишетмәдек. Хезмәткәрләр бары тик киштәләрне тутырырга гына өлгермиләр.

### Запас җитәрлек

Дөресен әйтергә кирәк, сәүдә челтәрләренең бер сатып алучыга бирелә торган товарлар күләмен чикләве халыкның күңеленә тагын да ныграк шом салды. Тик республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров аңлатуынча, вакытлыча чикләүләр мөһим товарларны барлык кешеләр дә сатып ала алсын һәм ыгы-зыгы аркасында әлеге төр продуктларга бәяләр артмасын өчен эшләнә. Ул шушындый ук хәлнең пандемия башында да булганлыгын искә төшерде. Министр фикеренчә, мондый ыгы-зыгы төрле имеш-мимешләр нигезендә барлыкка килә.

– «Сәүдә нокталарында теге яки бу товар бетә икән», – дигән сүз таралгач, халык кибеткә йөгерә. Әлеге очракта аеруча шикәр, карабодай, он турында сүз бара. Кибетләр билгеле бер план буенча эшли. Сатып алучылар киштәләрне бушаткач, кибет хезмәткәрләре аларны кабат тутырырга өлгерми. Кайвакыт киштәләрнең буш булуы шуңа гына бәйле, – ди ул.

Марат Җәббаров әйтүенчә, министрлыклар көн саен республикадагы товарлар күләмен анализлый. Бүгенгә барлык бүлеп бирү үзәкләрендә дә товар җитәрлек. Кибетләр белән җитештерүчеләр арасында килешүләр бар. Бәяләр тотрыклы.

– Карабодай, дөге, тоз, макарон эшләнмәләре запасы, менә мондый ихтыяҗ булган очракта да, ике айга җитәчәк. Хәзерге вакытта складлар өстәмә рәвештә тагын тутырыла. Шулай ук соңгы көннәрдә көнбагыш мае, шикәр, онны да күп алалар. Әлеге позицияләр буенча запас ким дигәндә ике айга җитә. Бүгенгә республиканың шикәр заводларында 11 мең тонна шикәр запасы бар. Икмәк

пешерү, социаль инфраструктура һәм ярминкәләр оештырыр өчен 2320 мең тонна шикәр кирәк. Шуңа күрә Татарстан Президенты күрсәтмәсе буенча, яңа уңыш җыеп алганга кадәр җитәрлек шикәр һәм ашлык резервы фонды булдыру турында килештек, – диде ул.

Министр сүзләре буенча, быел икмәк пешерүчеләргә ярдәм йөзеннән, 300 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Бу социаль төрдәге икмәккә һәм икмәк-күмәч эшләнмәләренә бәяләр артуны тоткарларга ярдәм итәчәк. Сөт ризыкларына бәяләр үсмәсен өчен, сөтчелек тармагына да ярдәм чаралары булдырылачак. Боларга өстәп, 19 мартта Татарстанда традицион ярминкәләр башлана. Анда, гадәттәгечә, азык-төлек арзанрак бәядән сатылачак.

– Бу вазгыятьтә халыкка мөрәҗәгать итеп, ясалма ыгы-зыгы тудырмауларын сорыйм. Республика азык-төлек белән җитәрлек тәэмин ителгән. Төп продукция – ит, сөт, шикәр комы, ярмалар, яшелчә, кош ите, он – барысы да бар, – диде министр.

Казан федераль университетының Идарә итү, икътисад һәм финанс институты профессоры Игорь Кох та җитәкченең фикерен куәтләде.

– Халык дөрес булмаган хәбәрне я вазгыятьне белеп бетермичә, яки хәлне тагын да кискенләштерер өчен махсус тарата, – ди ул. – Шуңа күрә коткыга бирелүнең бер мәгънәсе дә юк. Сату челтәрләрендәге вазгыять үзгәрсен өчен бер сәбәп тә юк. Бу эшләр, гадәттә, бәяләрне тотрыклы итәр өчен эшләнә. Чөнки башкача булганда кемдер моннан оста файдаланырга мөмкин.

### Контроль көчле

Азык-төлек запасы һәм бәяләр тирәсендәге хәлләрне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үз контроленә алды. Бәйрәм көннәрендә ул Казан сөт комбинатында һәм Кумәч-кондитер комбинатында булган иде. Аңа эшләп чыгарыла торган продукция күләмен арттырырга җыенулары хакында хәбәр иттеләр. Коллектив белән аралашу барышында Рөстәм Миңнеханов башкарылган эшнең мөһимлеген аерым билгеләп үтте.

– Безнең республика барлык төп азык-төлек продуктларын җитештерү буенча беренче урыннарны били. Без үзебезне тулысынча үзебез тәэмин итәбез. Алга таба да җитештерүләр үсешенә ярдәм итәчәкбез, – диде Президент.

Шулай ук республикада Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе белән ике комиссия төзелде. Аның берсе – азык-төлек, икенчесе азык-төлек булмаган товарларга кураторлык итәчәк. Әлеге комиссияләр зур сәүдә челтәрләрендә дә, муниципалитетлардагы зур булмаган кибетләрдә дә бәяләргә атна саен (элек ул ай саен уздырыла иде) мониторинг үткәрә. Президент хәзерге вакытта ихтыяҗ зур булган (аерым алганда, шикәр комы һәм он) азык-төлек продукциясенең кибет киштәләрендә җитәрлек күләмдә булуын тәэмин итү бурычын куйды. Комиссия шулай ук азык-төлек булмаган товарларның кибеттә булуын һәм 52 позиция буенча аларның бәясен дә контрольдә тота. Әйтик, юу чаралары. Алар белән барлык кибетләрне тәэмин итү өчен «Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыяте (400 исемдә продукция җитештерә) җәлеп ителгән.

Билгеле булганча, бәя билгеләү һәм товар кытлыгы мәсьәләләре Монополиягә каршы федераль хезмәтнең даими күзәтүендә тора. Бу көннәрдә әлеге оешма вәкилләре Авыл хуҗалыгы, Сәнәгать һәм сәүдә министрлыклары вәкилләре белән бергәләп кибетләрне йөреп чыкты. Һәм сәүдә нокталарында да, бүлеп бирү үзәкләрендә дә товар кытлыгын күрмәде.

Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Андрей Розенталь әйтүенчә, соңгы көннәрдә шикәр, он кытлыгы буенча халыктан килгән мөрәҗәгатьләр саны арткан.

– Халыкның товар бетә, дип хафалануын аңлап та була, чөнки валюта сикерә, мәгълүмат юк. Шуңа күрә кибеткә барып, артыгы белән продукция сатып ала. Бер атна элек запас бик күп иде. Билгеле, гадәттәгедән тыш күпләп ала башлагач, бүлеп бирү үзәкләреннән товарны китереп җиткермиләр, – диде ул.

Билгеле булганча, гыйнварда ук сәүдә челтәрләре белән билгеле бер бәядән арттырмаска дигән килешү төзелгән иде. Ыгы-зыгыга карамастан, соңгы көннәрдә беренче чиратта кирәкле товарларның күпчелегенә бәяне кискен арттыру очраклары күзәтелмәгән.

– Бер төрдәге товарларга бәя җитештерүчегә карап аерыла. Арзангы бетәргә, ә кыйммәтрәк булганы киштәдә калырга мөмкин. Федераль челтәрләрдә шикәргә бер төрлерәк бәя куела. Мәсәлән, килограммы 56–58 сум тора. Ыгы-зыгы кимегәч тә, аның бәясе үзгәрешсез калыр, дип уйлыйм. Ләкин соңгы берничә көн эчендә аларны күпләп алдылар. Шунлыктан, чыннан да, кайбер кибетләрдә бу төр товарларга кытлык бар. Бу бары тик бүлеп бирү үзәкләреннән товарны китереп өлгермәүгә генә бәйле. Безгә җиткерелгән мәгълүматлар буенча, шушы берничә көн эчендә мондый проблема бетәчәк. Шуңа күрә халыкка тагын бер кат мөрәҗәгать итәбез: запаска дип 10–20 кап шикәр алырга йөгерергә кирәкми. Бу проблема бер атна элек тә юк иде, хәзер дә юк. Безнеңчә, вазгыять ясалма күпертелгән. Халык бер-берсеннән күреп йөгерә. Ыгы-зыгы тудырырга бер сәбәп тә юк, – диде җитәкче.

Шул ук вакытта Андрей Розенталь әйтүенчә, карабодайга бәя арткан. Ләкин белгеч фикеренчә, моңа халык үзе гаепле.

– Мондый вакытта гадәттә карабодайга һәрвакыт бәя арта. Кайбер кибетләр шикәр бәясен дә күтәрде. Моның сәбәбе – ясалма рәвештә барлыкка китерелгән ыгы-зыгы гына. Шуңа күрә якын көннәрдә товар бәяләре бик нык артачак, дигән курку урынлы түгел. Бәяләр, гадәттә, товар җитмәгән (дефицит) яки читтән кертелгән очракта арта. Складларда бар икән, бәя артуга сәбәп юк. Ә бездә мөһим булган азык-төлек товарлары барысы да Россиядә җитештерелә. Бераз үзгәрешләр булса да, безнең предприятиеләр, доллар тирбәнүеннән китәр өчен, бу шартларга яраклашыр дип уйлыйм, – диде ул.

Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова кичә журналистлар белән очрашуда товарларга бернинди дә кытлык юклыгына һәм моннан соң да булмаячагына кабат басым ясады.

– Складларда 200 көнгә җитәрлек товар бар. Әгәр ихтыяҗ тагын да булса, аларны өстәмә рәвештә тутырырга әзербез. Икмәк һәм сөт ризыклары гадәти режимда әзерләнә. Президент үзе моңа инанды. Бүгенгә күләмнәре кимеми. Алай гына да түгел, Казан сөт комбинаты һәм Кумәч-кондитер комбинаты җитәкчеләре җиткерүенчә, инвестицион программалар һәм дәүләт ярдәме хисабына җитештерү цехларын яңарту бара. Бу продукция күләмен арттырырга булышачак. Ягъни без күбрәк ипи һәм сөт ризыклары җитештерергә, аларны төрләндерергә әзербез, – диде Лилия Галимова.

Зөһрә САДЫЙКОВА

# БАЛАЛАРГА ЯРДӘМ

**Быел 8 мартта гүзәл затлар яхшы хәбәр алды. Шушы көнне Россия Президенты Владимир Путин 8–16 яшьлек балалары булган гаиләләргә яңа төр пособие түләнә башланачагын хәбәр итте. Ил күләмендә ул 5 миллионнан артык балага түләнәчәк.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа төр пособие аз керемле гаиләләргә исәпләнгән. Ярдәм 1 апрельдән билгеләнә. Аны алу өчен гаризаларны 1 майдан кабул итә башлаячаклар. Пособие буенча беренче түләүләр дә май аенда күчәчәк дип планлаштырыла.

Россия Хезмәт министрлыгы башлыгы Антон Котяков сүзләренә караганда, пособиенең төп күләме бер балага төбәк яшәү минимумының (Татарстанда 10433 сум) яртысын тәшкил итәчәк. Әгәр бу күләмдә пособие билгеләнгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган уртача кереме яшәү минимумыннан кимрәк булса, пособие төбәктәге яшәү минимумының 75 проценты күләмендә билгеләнәчәк. Әгәр бу вакытта да гаилә керемнәре төбәк яшәү минимумыннан азрак булса, әти-әни төбәк яшәү минимумының 100 проценты күләмендә пособие ала алачак.

Әлеге пособиене алу өчен, «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша онлайн рәвештә гариза тапшырырга кирәк. Пособие «Мир» картасына күчереләчәк. «Пособие буенча беренче түләүләр май аенда килеп ирешәчәк. Әмма ул 1 апрельдән исәпләнәчәк. Шуңа күрә майда акча берьюлы ике ай – апрель һәм май өчен күчәчәк. Пособие алуга гаризаны май ахырында гына язган кеше исә берьюлы өч ай өчен акча алачак», – ди министр.

Баланың пособие алуга лаекмы-юкмы икәнлеген ачыклаганда, гаиләнең айлык кереме, ата-ананың кайда, күпме табыш алып эшләве, милке дә исәпкә алыначак. Аларның рәсми кереме булмаган очракта, аның җитди сәбәбе булырга тиеш. Пособие бер елга билгеләнә. Аннан соң аны яңадан рәсмиләштерергә кирәк булачак.

# ДАРУГА КЫТЛЫК ЮК

**Соңгы арада халык азык-төлек кенә түгел, кырып-себереп, дару да җыя башлаган! Ун көн эчендә республикада даруларга ихтыяҗ ике тапкыр арткан. Бу хакта кичә журналистларга Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева сөйләде.**

«Республиканың дәүләт даруханә складында гомуми суммасы 2 миллиард сумнан арткан дару запасы бар. 6,6 миллиард сумга төзелгән 2,5 мең дәүләт килешүенең яртысы буенча дарулар китерелде инде. Хәзерге вакытта да дарулар белән тәэмин итү дәвам итә», – дип белдерде Фәридә Яркәева.

Министр урынбасары сүзләрен «Таттехмедфарм» унитар дәүләт оешмасының даруханә склады буенча генераль директоры урынбасары Илшат Минһаҗетдинов да куәтләде. Татарстан дарулар һәм медицина кирәк-яраклары белән тулысынча тәэмин ителгән, дип ышандырды ул. Билгеле булганча, «Таттехмедфарм» бүген республиканың медицина оешмаларын дарулар һәм медицина кирәк-яраклары белән тәэмин итүче бердәнбер оешма булып тора.

«Без үзебезнең дистрибьютерлар белән генә эшлибез, читтән дару кертмибез», – дип сөйләде ул журналистларга. Илшат Минһаҗетдинов сүзләренә караганда, соңгы елларда үзебездә һәм чит илдә җитештерелгән дарулар тигез күләмдә кайтарылган. Шул ук вакытта чит ил даруларының да күбесе Россия территориясендә җитештерелгән. «Безнең илгә карата кертелгән чикләүләр даруларга кагылмады. Шулай да, бүген логистиканың бозылуын исәпкә алсак, бу юнәлештә тоткарлыклар булырга мөмкин», – дип кисәтте ул. Ташламалы даруларга да кытлык булмаячак дип ышандыра Илшат Минһаҗетдинов.

Бу көннәрдә халык, бөтен нәрсәгә бәя артканда, дарулар да кыйммәтләнер инде, дип борчыла. Әмма «Таттехмедфарм» оешмасында куркырга җирлек юк, дип ышандыралар. «Бүген ташлама буенча ярты елга җитәрлек дару бар, дарулар ваклап сатарга да җитә. Хәтерлисезме, коронавирус башлангач та шундый ук шау-шу күзәтелгән иде. Халык киштәдәге бөтен товарны кырып-себереп алып бетерде дә, соңрак алар барысы да чүплектә урын алды. Һәр товарның яраклылык вакыты бар бит. Шуңа күрә халыкны тынычландырасым килә: даруларны да кирәгеннән артыграк күләмдә алып куярга кирәкми», – диде Илшат әфәнде.

Оешма вәкиле республика хастаханәләренә дә дарулар вакытында килеп торачак дип вәгъдә бирде. «Яшәү өчен мөһим булган дарулар бәясе үзгәрә алмый, бәяләр теркәлгән, җитештерүчеләр аларны элеккеге бәядән китерә. Безнең складта өстәп куелган бәя дә үзгәрми, ул Тарифлар комитеты тарафыннан законлаштырылган. Бәйләү чаралары, система, шприц кебек кирәк-яраклар кыйммәтләнер, мөгаен. Әмма әлегә аларны иске бәядән китерәләр», – дип сөйләде директор урынбасары.

«Таттехмедфарм» тараткан даруларның 80 процентын яшәү өчен мөһим булган препаратлар тәшкил итә. Даруларга бәяне арттырырга җыенмыйлар. Аларның хаклары юл чыгымнары аркасында гына бераз кыйммәтләнергә мөмкин, дип фаразлый белгечләр. Анысы да 10 проценттан артмас дип ышандыралар. Бүген даруханәләрдә инсулинга аеруча сорау зур икән. Әмма Илшат Минһаҗетдинов, ул беткән очракта да даруханәләргә тиешле күләмдә кайтарылачак, дип ышандыра. Хәвефләнеп, шау-шу тудырырга кирәкми, кыскасы.

## 14 март | Дүшәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.15 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.30 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
17.00 «Мин» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Вехи истории» 12+
00.45 «Соотечественники» 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.35, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
23.25 «Большая игра» 16+
00.25 К юбилею Наины Ельциной. «Объяснение любви» 12+
03.00 Новости

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.00 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
03.40 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 08.30, 12.25, 14.50, 22.00 Новости
06.05, 22.05, 01.15 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Биатлон. Кубок России. Финал. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Уфы
10.00 Смешанные единоборства. UFC. Тиаго Сантос против Магомеда Анкалаева. Трансляция из США 16+
11.05 Биатлон. Кубок России. Финал. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Уфы
12.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30, 03.55 Специальный репортаж 12+
13.50, 01.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
14.55 «ВОИН» 12+
17.50 Профессиональный бокс. Мэнни Пакьяо против Йордениса Угаса. Трансляция из США 16+
19.00 «Громко». Прямой эфир
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
22.40 Футбол. Кубок Шотландии. 1/4 финала. «Данди Юнайтед» – «Селтик». Прямая трансляция
00.45 Тотальный футбол 12+
02.45 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Нижний Новгород» – УНИКС (Казань) 0+
03.50 Новости 0+
04.10 «Несвободное падение. Олег Коротаев» 12+

### НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.30 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «ПРОПАВШАЯ НЕВЕСТА» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Банка с пауками» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «НИКОГДА НЕ БЫВАЕТ ПОЗДНО» 16+
19.00 «САШКА» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2» 16+
01.50 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.00 «Нулевая мировая» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «ВА-БАНК» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.35 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05, 03.50 «ХУТОРЯНИН» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Витебск» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №94». Премьера! 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Нюрнберг. Свидетель Паулюс». Премьера! 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.40 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
01.15 «ЮНОСТЬ ПЕТРА» 12+
03.30 «Москва фронту». Док. сериал 16+

## 15 март | Сишәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». «Мудрость от родной земли. Туфан Миннуллин» 12+
00.40 «Вехи истории». Там, где в Каму врезаются лодки 12+
01.05 «Реквизиты былой суеты» 12+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.30, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
23.25 «Большая игра» 16+
00.25 «Николай II. Последняя воля императора» 16+
03.00 Новости

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.00 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
03.40 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.25, 14.45, 17.50, 22.00 Новости
06.05, 20.05, 22.05, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ВОИН» 12+
11.55 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Фабрисио Вердума. Трансляция из Великобритании 16+
12.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30, 03.50 Специальный репортаж 12+
13.50, 14.50 «ПРАВИЛА ОХОТЫ. ОТСТУПНИК» 16+
17.30, 17.55 «НОЧНОЙ БЕГЛЕЦ» 16+
20.25 Гандбол. Чемпионат России «Олимпбет-Суперлига». Женщины. ЦСКА – «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Манчестер Юнайтед» (Англия) – «Атлетико» (Испания). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Аякс» (Нидерланды) – «Бенфика» (Португалия) 0+
03.45 Новости 0+
04.05 «Несвободное падение. Кира Иванова» 12+
05.05 «Наши иностранцы» 12+
05.30 «Голевая неделя» 0+

### НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Бег по острым камням» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «ПРОБУЖДЕНИЕ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «КОГДА УМРЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
23.05 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 43-я и 44-я серии 16+
01.00 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.10 «Эффект Матроны» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ХУТОРЯНИН» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.25 «ВА-БАНК 2, ИЛИ ОТВЕТНЫЙ УДАР» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.35, 03.40 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05, 03.50 «ХУТОРЯНИН» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Малая земля» 16+
19.40 «Легенды армии». Иван Яцуненко 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «КОЛЬЦО ИЗ АМСТЕРДАМА» 12+
01.25 «В НАЧАЛЕ СЛАВНЫХ ДЕЛ» 12+

# ЙОЛДЫЗНАМӘ 14–20 МАРТ

**КУЧКАР (21.03 – 20.04)**
Бу атнада гадәти кысага сыешмаган күп кенә вакыйгалар булачак. Гомумән, сезгә кагылышлы үзгәрешләр башланып китәчәк. Барысы да үзегезнең кыюлык һәм тәвәккәллеккә барып тоташачак.

**ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)**
Серләрегезне беркемгә, хәтта якын туганнарыгызга да вакытыннан алда ачып салмагыз. Юкса күңел сүрелү куркынычы юк түгел. Кафе-рестораннарда сак булу ягын карагыз, юкса ашказаны-эчәк системасы үзен сиздерергә мөмкин. Атна ахырында әйбәт яңалыклар көтегез.

**ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)**
Атна бер генә төрле узмастыр: ниндидер шикләнүләр, аңлап бетермәүләр булырга мөмкин. Иң мөһиме – яңа эшкә тотынмау, юкса кинәт кенә баш калкыткан кыенлыкларга юлыгу куркынычы бар... Атна ахырында үзегезгә карата сәеррәк, әмма алга таба үсү өчен бик кирәкле фикерләр ишетәчәксез.

**КЫСЛА (22.06 – 22.07)**
Бурычлар атнасы. Булса соң – алар искиткеч зур канәгатьлек хисе белән үтәләчәк. Ләкин якыннарыгыз белән үзара аңлашылмаучанлык кына килеп чыгарга мөмкин. Сәбәбеме? Күзгә карап алдашу...

**АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)**
Акча мәсьәләсендәме ул, мәхәббәт «фронт»ындамы – һәркайда моңарчы күрелмәгән биеклекләргә ирешәчәксез. Әле тагын сизгеррәккә дә әйләнәчәксез! Бигрәк тә – юлда. Өс-башыгызны яңарту теләге туар: моның өчен акчасы да, башкасы да бик җиңел табылыр.

**КЫЗ (24.08 – 22.09)**
Кыюсызрак булуыгыз бераз гына кыенлыклар китереп чыгармагае. Килеп туган теләсә кайсы хәлләрдә бирешергә ярамый: хаклык сезнең якта! Ялгызлар үзләренә тиң ярларын очратачак, ә гаиләлеләргә бер-берсен тагын да күбрәк ярату, ихтирам итү өчен шәп кенә сәбәпләр чыгачак.

**ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)**
Карьера баскычыннан югарырак үрмәләү авыргарак туры килә башладымы? Күңелегезгә ниндидер шикләр кереп оялаган вакыт шул... Хафаланасы юк: инде атна уртасында, үзегезне балаларча сөендереп, күп кенә нәрсәләр ачыклана башлаячак.

**ЧАЯН (24.10 – 22.11)**
Тормышыгыздагы кара полосаның кардай агына алышынуына күп калмады бугай... Һәрхәлдә, атна башындагы бер проблеманың очына чыгу шуны расларга тиеш. Ә инде атна ахырында колагыгызга чалынган әйбәт кенә яңалыклар үзегезгә гүя канатлар куячак.

**УКЧЫ (23.11 – 21.12)**
Көтмәгәндә генә ныклыкка сынау узарга туры киләчәк. Әйтергә кирәк, аны сез искитмәле дәрәҗәдә матур һәм оста итеп башкарып чыгачаксыз. Әҗере дә мулдан булачак...

**КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)**
Туктап калып, күптәнге хаталарыгызны төзәтергә туры килмәгәе. Атна уртасында беравык эшегез бармый кебек тоелыр, хезмәттәшләрегез белән бераз әйткәләшеп алулар да булыр. Ә инде шуннан соң берсеннән-берсе яхшырак вакыйгалар башланып китәр.

**СУКОЯР (21.01 – 19.02)**
Гади, әмма бик күңелле, бәрәкәтле чор. Кинәт кенә башыгызда туган уй изге бер гамәлгә этәрер. Әлбәттә, сез аның өчен кызармаячаксыз, бәлки иксез-чиксез горурлык хисләре кичерәчәксез!

**БАЛЫК (20.02 – 20.03)**
Хисләргә бирелеп алырга туры килмәгәе. Вакыты шундыйрак чөнки... Ерактан ишетелгән бер хәбәр күңел кылларыгызны тибрәтеп җибәрер. Кыскасы, бик хисле һәм хикмәтле чор.

КҮПЛӘП САТЫП АЛУЧЫЛАР БӘЯСЕННӘН

➢савыт-сабалар
➢электр товарлары
➢йорт кирәк-яраклары
➢люстралар
Казан шәһәре, ТЭЦ урамы, 175 нче йорт.
«У РИЗИДЫ», 1,2,3 нче кибет складлары.
89673795721; 898774107755
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» промокоды белән 5% ташлама
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

# БАЛА ЙӨРӘГЕН ДӘ АЯМЫЙ

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Коронавирус дигән зәхмәт үзе бер авыр булса, аннан соң тернәкләнү чоры организм өчен икеләтә зур сынауга әйләнә. Галимнәр, әлеге чир белән авырып терелгән кешеләрнең 20 процентында коронавирустан соң пәйда була торган билгеләр күзәтелә, ди. Балалар постковид чорын ничек уздыра?**

**Республика балалар клиник хастаханәсенең изоляция-диагностика бүлеге мөдире Лилия ЗЫЯТДИНОВА «ВТ» хәбәрчесенә әнә шул хакта сөйләде.**

**Кемнәрдә ешрак очрый?** Чирне җиңелчә формада уздырган балаларда коронавирустан соңгы өзлегүләр дә сирәгрәк күзәтелә. Шул ук вакытта балалардагы постковид чоры әле ахыргача өйрәнелеп бетмәгән. Әмма шунысы тәгәл билгеле: 13–17 яшьлек үсмерләр чиргә аеруча тиз бирешә. Бронхиаль астма, бронхит, хроник бөер, йөрәк-кан тамырлары авырулары булган, артык авырлыктан, шикәр чире, яман шештән интеккән балалар сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк.

**Ашказаны-эчәк трактына «бәрә».** Коронавирустан соңгы синдром (постковид) дигән төшенчә – ковид белән авырып терелгәннән соң, ким дигәндә дүрт атна үткәч, организмда күзәтелә торган физик һәм психик билгеләрдән гыйбарәт. Балаларда ул күбрәк ашказаны-эчәк трактына «бәрә». Коронавирус белән авырып терелгән балалар еш кына эч сыеклану, эчәклек ялкынсынудан тилмерә. Ата-ана моны еш кына гадәти энтеровирус дип уйлап ялгыша.

**Mis-C (мультиялкынсыну) синдромы пәйда була.** Коронавирус белән авырып терелгән балалар һәм яшүсмерләр организмында еш кына әнә шундый үзгәреш тә күзәтелә. Пандемия чорында пәйда булган яңа төшенчә бу. Ул иммунитетның коронавирустан соңгы өзлегүләргә җавабы булып тора. Ул, гадәттә, Кавасаки синдромы (кан тамырлары ялкынсыну. – **Д.Г.**) вакытында күзәтелгән билгеләр белән уза: температура күтәрелә, кан ялкынсына, күп кенә органнар зарарлана. Балаларда алар чир белән авыргannan соң өч-дүрт атнадан күзәтелергә мөмкин. Моннан тыш Mis-C синдромы йөрәк-кан тамырлары эшчәнлегендә дә хилафлыклар китереп чыгара ала. Баланың йөрәк тибеше начарлана, кан тамырлары кинәю куркынычы арта.

**Үпкәләр зарарлана.** Коронавирус белән авыру озакка сузылган очракта, балада күкрәк читлеге авырту, ютәл, тын кысылу кебек билгеләр күзәтелә ала. Бу билгеләрнең кайберләре өч ай дәвамында сакланырга мөмкин. Ковид белән авырып терелгән баланың йөрәге дә зәгыйфьләнә. Анда еш кына миокардит (йөрәк мускулы ялкынсыну) билгеләре күзәтелә – күкрәк читлеге авырта, тыны кысыла, йөрәк тибеше начарлана, тиз арый. Аеруча җитди очракларда миокардит йөрәк өянәге, инсульт, йөрәк туктауга да китерергә мөмкин.

**Хроник арыганлык борчый.** Коронавирус белән авырып терелгән бала еш кына хроник арыганлыктан да интегә. Араларында кан басымы уйнау, авырдан сию, ис, тәм сизмәүдән зарланучылар да байтак. Билгеле булганча, ковид белән авырган өлкәннәр терелгәннән соң хәтерсезлектән, йокысызлыктан интегә, игътибарсызга әйләнә. Балаларда да еш кына бу чорда әнә шундый билгеләр күзәтелә. Хроник арыганлыктан котылу өчен баланың көндәлек режимын җайга салырга, акрынлап физик активлыкны киметергә кирәк.

> **Табибтан өч киңәш**
>
> ✹Коронавирустан соң өзлегүләр булмасын өчен беренче билгеләр күзәтелүгә үк табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Баланы үзең белүеңчә дәвалау куркыныч.
>
> ✹Бу максатта вакцина ясатудан да нәтиҗәлерәк профилактика чарасы юк. Билгеле бер сәбәп аркасында балага коронавируска каршы прививка ясарга ярамаса, аңа якыннары ярдәмгә килә ала. Алар вакцина ясаткан булса, баланың чир йоктыру ихтималы да кими. Битлек кию, социаль дистанция саклау да – чирне иң яхшы кисәтү чарасы.
>
> ✹Коронавирус белән авырган балалар һәм яшүсмерләр участок табибында яки педиатрда ким дигәндә бер тапкыр булса да контроль тикшерену узарга тиеш. Авырганнан соң саклангaн билгеләрне күзәтеп тору, яңаларын кисәтү өчен кирәк бу.

Сорау – җавап

## Чәч турында 5 сорау

**Яшерен-батырын түгел, чәчләребез – матурлык кына түгел, сәламәтлек билгесе дә. Алар матур һәм сау-сәламәт булсын өчен ни эшләргә? Бүген укучыларыбызны кызыксындырган иң төп сорауларга җавап табарга булдык. Сорауларга табиб-трихолог Елена Маркова җавап бирә.**

pixabay.com

**1. Чәч коелудан ничек котылырга?**
Күпчелек очракта чәчләр тышкы факторлар нәтиҗәсендә түгел, ә эчке проблемалар йогынтысында коела. Шулай да, чәчләр күп коела икән, шампуньны алыштырып карарга, кан йөреше яхшырсын өчен баш тиресенә массаж ясарга була. Бу очракта кондиционер, маскалар кулланмагыз. Кимеп баручы ай фазасында чәчләрне кистерү дә чәч коелудан коткара ала.

**2. Чәчләрне никадәр еш кистерергә кирәк?**
Чәчләрен үстерергә теләүчеләр, аларның очы тигез булсын һәм икеләнмәсен өчен, һәр 3 ай саен кистереп торырга тиеш. Чәч озынлыгын уртача зурлыкта тотарга һәм гел бер формада йөртергә теләгәннәргә ай ярымнан соң кабат чәчтарашханәгә барырга киңәш ителә.

**3. Хатын-кызга ир-ат шампуне белән чәч юарга ярыймы?**
Ярый гына түгел, кирәк тә. Ир-атлар өчен чыгарылган шампуньнарда артык силиконнар һәм дым бирүче матдәләр булмый. Гомумән, шампунь сайлауны составын өйрәнүдән башлагыз. Иң әлек интернеттан чәчләр өчен зарарлы кушылмалар белән танышыгыз, аеруча зарарлыларын язып алыгыз.

**4. Өй шартларында чәчләрне ничек тәрбияләп була?**
Өй шартларында тәрбияләнгән чәчләр дә салоннарда матурайтылганнан әллә ни аерылмый. Аптекадан капсулада сатыла торган А һәм Е витаминнарын чәчләр өчен маскага, тәнгә сөртә торган кремнарга кушып кулланырга була.

**5. Баш тиресе дә тәрбиягә мохтаҗмы?**
Һичшиксез мохтаҗ! Кыш һәм җәй көннәрендә аңа аеруча игътибарлы булырга кирәк. Баш тиресен тышкы факторлардан саклау өчен махсус чаралар – косметик кремнар, спрей яки майлар кулланырга мөмкин. Иң җайлысы спрей, билгеле. Ул текстурасы һәм тигез җәелүе белән уңайлы.

Абау!

### Көнбагыш сәбәпче

Көнбагыш ашарга яраткан кешенең сукыр эчәгесе шартларга мөмкин. Күптән түгел Төркиянең Измир шәһәре белгечләре шундый нәтиҗәгә килгән. Белгечләр соңгы җиде елда сукыр эчәгенә операция ясаткан ике меңгә якын кешене тикшергән. Тикшерену нәтиҗәләре сигез кешегә операциянең нәкъ менә сукыр эчәгенә эшкәртелмәгән көнбагыш калдыклары җыелу аркасында ясалганлыгын ачыклаган. Тагын бер кешенең пычак астына ятуына җиләк-җимеш төше сәбәпче булган.

Үзем сынадым

## Күздәге «капчык»лар бетте

Күз төбемдә «капчык»лар пәйда булып интектерә. Аларны әнә шушы ысуллар ярдәмендә җиңәм. Суыткычта торган кыярны түгәрәкләп кисәм дә, шуны күз төпләренә куеп, 15 минут ятып торам. Угычтан чи бәрәңге уып, шул ботканы 10–15 минутка күз төбенә куеп торуның да файдасы тигәне бар. Вак итеп туралган петрушканы 2 чәй кашыгы каймак белән бутап, күз кабакларына куеп торсагыз да «капчык»лар юкка чыгачак.

Гөлназ ГЫЙЛАҖИЕВА.
Арча

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Исеңдә тот!

## Орлыкларга – водород перекисе

Чәчәр алдыннан орлыкларны водород перекисенда тоту әйбәт. Болай эшләгәндә, алар тиз тишелә, бактерияләрдән арына, авыруларга бирешмәүчәнгә әйләнә. Моның өчен бер стакан суга бер чәй кашыгы перекись салырга һәм, орлыкларны марляга төреп, шушы эремәдә тотарга кирәк. Авыррак тишелә торганнарын (әйтик, петуния, кишер, петрушка, укроп орлыклары) – 5 сәгать, тиз тишелә торганнарын 2–3 сәгать тотарга. Эремәдән алгач, марля төенчекне чиста суда чайкатып алырга һәм орлыкларны кәгазь салфеткаларга салып киптерергә.

Хуҗабикәгә

## СОДА ЧИСТАРТА

Сода суыткыч эчен бик ансат чистарта һәм тәмсез исләрдән котылырга ярдәм итә. Кипкән һәм каткан тапларны бетерү өчен соданы бераз җылы су белән бутап, кефир төсле масса булганчы болгатыгыз. Әлеге «ботка»ны марляга сылап, тап булган урынга 30 минутка куеп калдырыгыз. Аннан соң таплы урынны әлеге марля белән ышкыгыз һәм җылы су белән сөртеп алыгыз. Суыткычыгыз әллә нинди көчле химияләрсез генә ялт итәчәк.

Белеп тор!

## МИЛӘҮШӘ ЧӘЧӘК АТМАСА

Миләүшә (фиалка) шау чәчәктә утырсын өчен, беренчедән, аны кечкенә савытка утыртырга кирәк. Зур савытта яфракка котыра, үги ботакларын күп җибәрә, әмма чәчәк атый. Икенчедән, үги ботакларын өзеп торырга. Үги ботакны чәчәк яфрагы белән бутамаска. Чәчәк яфрагы – очлырак, үги ботак яфрагы түгәрәк булып үсеп чыга. Үги ботакны төбеннән пинцет белән йолкып алырга (төбе калса, гөл чирләячәк) һәм шул урынга активлаштырылган күмер сибеп куярга кирәк. Аннан килеп, гөл туфрагын ике елга бер мәртәбә алыштырып торырга. Күчереп утыртканда, аскы рәтләрдәге яфракларны өзеп, өске яшь яфракларын гына калдырырга киңәш ителә. Болай эшләгәндә, миләүшәләр ел дәвамында чәчәк атып утырачак.

# МАРТТАН КАЛМАСЫН

**«Нинди бакча эшләре?!» – диярсез инде. Чыннан да, кар катламы кышкы айлардагыдан да калынрак бит. Бураннар да котырып тора. Әмма март – ничек кенә булса да, тәүге яз ае. Аның якынлашуы барыбер сизелә. Айның икенче яртысында кар акрынлап утыра һәм эри башлый.**

**Яшелчә**

Бу айда яшелчә үстерүченең төп игътибары ачык грунтта утыртылырга тиешле яшелчә культураларының үсентеләрен өй шартларында, иртә парникларда, теплицаларда үстерүгә юнәлгән була. Өй шартларында иртә өлгерә торган помидорны үсенте өчен – март башында, соң өлгерешле сортларын 18–21 мартта чәчәләр, ә баклажан, баллы борыч инде март башында беренче чын яфрагын чыгарып өлгерә. Иртә парникларда март башында иртә өлгерешле кәбестә үсентеләрен, шулай ук яшел килеш файдалану өчен редис, кыяклы суган, салат һәм шпинат кебек культураларны чәчү башлана. Шулай ук ачык грунт өчен минераль ашламалар әзерләүне дәвам итәргә, кар тотарга кирәк. Моның өчен кар өстенә тасма-тасма итеп черемә яисә көл сибәләр, кардан валлар ясыйлар. Март ахырында пленкалы теплицаларга рамнар куялар.

**Агач-куаклар**

Бу чорда җимеш агачларын һәм куакларны санитар кисү көтә. Бакчада булган карны бакча җиләге һәм кура җиләге төпләренә өяргә тырышыгыз. Шулай ук карлыган куакларын тикшерегез. Әгәр аларда кабарган-бүрткән бөреләр күренә икән, аларны юк итегез. Болай иткәндә сез бөре талпанынннан котылырсыз.

Яшелчәләрне иртәрәк чәчәргә исәпләгән түтәлләр өстенә торф яки көл сибеп куегыз. Алар карга тизрәк эрергә ярдәм итәчәк.

Бакчаны корткычлардан һәм авырулардан саклауны яз көне үк кайгыртсагыз, үсемлекләр сәламәт булачак һәм мул уңыш бирәчәк. Бакчага табигый ашламалар гына кертергә тырышыгыз. Карлыган куакларын суган кабыгы төнәтмәсе (10 л суга 200 г) белән эшкәртегез. Талпаннарга каршы канлы үлән (чистотел) төнәтмәсе (10 л суга 50 г канлы үлән), онсыл чыкка каршы көл (1 л суга 1 стакан көл) кулланыгыз. Чәчәк аткан вакытка кадәр шулай итеп эшкәртергә мөмкин. Сөяк, көнкүрештәге табигый чүпләрне, корыган ботакларны җыеп, барысын бергә ягыгыз. Барлыкка килгән көл белән үсемлекләрне дә, туфракны да ашларга була. Искергән иписе кисәкләрен күгәрмәсен өчен мичтә киптерегез дә пакетка җыеп барыгыз. Җәй көне ул ипи калдыкларын үсемлекләргә ашлама буларак файдаланырга мөмкин. Аның өчен ипине җылы суга салып, төне буе җебетегез. Иртә белән барлыкка килгән катнашманы туфракка сибегез, мәсәлән, җирне йомшартканда, мулчәләгән вакытта. Ипи калдыклары тулысынча эреп юкка чыккан суны үсемлекләргә сибү өчен дә кулланырга мөмкин.

Бакчадагы җимеш агачларын һәм куакларны һәр яз саен чистартып торырга кирәк.

Агачларны корыган яфраклардан, кипкән җимеш калдыкларыннан арындырыгыз һәм җыеп яндырыгыз. Аларда авыру барлыкка китерүчеләр булырга мөмкин.

Корыган, сынган һәм кәкре ботакларны кисеп алу да артык булмас.

Кайрыдагы ярыклар, буразначыкларны тикшереп чыгыгыз. Яшеренгән корткычларны җыеп юк итегез. Март – бакчачы өчен иң җаваплы һәм мәшәкатьле айларның берсе. Бу чорда аеруча җимеш агачларын сакларга киңәш ителә: кояш нурларының кәүсәләргә зыян китерүе бар.

**Чәчәк**

Март ахырында кашкарый (астра) һәм бәрхет гөл (бархатцы) орлыкларын утыртыгыз. Аларны 1,5 см тирәнлектә туфракка чәчеп, су сибеп, өстен тигезләп, пленка белән каплап, җылы урынга урнаштырыгыз.

Мартта гладиолус, суган, георгиннарны тагын бер кат тикшерегез. Барлык чирле өлешләрен сәламәт тукымаларга кадәр чистартып, киселгән урыннарны зеленка белән зарарсызландырыгыз һәм кабат саклауга салыгыз.

Гүзәл ӘХМӘТҖАНОВА
әзерләде

vk.com

## БӨҖӘКЛӘРДӘН КОТКАРАБЫЗ

Март аенда иң мөһим эшләрнең берсе – агачларны ботакларда һәм җирдә кышлаучы зарарлы бөҗәкләргә каршы эшкәртү. Моның өчен түбәндәге рецептны кулланырга була.

✓ 700 грамм мочевинаны 10 литр салкын суда эретеп сөзегез дә, шушы состав белән бакчада үскән бар агач-куакларны һәм кардан ачылган туфракны эшкәртеп чыгыгыз. Минераль ашламаның мондый концентрациясе бөҗәкләрнең тиресе аша үтеп кереп, тоз алмашын бозачак һәм алардан котылырга булышачак. Ә йоклаган чорда сибү үсентеләргә һичбер зыян китермәячәк.

✓ Агачларыгызда лишайниклар күп икән, аларны тимер купоросының 7–10 процентлы эремәсе белән эшкәртергә киңәш ителә (100 грамм суга 1 чәй кашыгы). Кәүсәләрне пумала белән дә, сиптереп тә эшкәртергә була. Өч көн үтүгә, лишайниклар агачтан үзләре коелып төшәчәк.

**Искәрмә:** бу эшкәртү чараларын агачларда сут йөреше башланганга кадәр үткәрергә кирәк. Юкса, сут агышы башланса, бөреләрне яндырып харап итүегез бар. Хәтта агачның коруы ихтимал.

Тәмле булсын!

## *Бавыр коймаклары*

**Рәмзия Әхмәдуллина рецепты**

**Кирәк:** *1кг бавыр, 2 йомырка, 2 баш суган, 5 аш кашыгы он, тәменчә тоз, борыч, 2 аш кашыгы үсемлек мае.*

Бавырны суган кушып, иттарткыч аша чыгарабыз. Аннары барысын бергә кушып болгатабыз. Кызган, майлы табада коймак кебек пешерәбез. Бер ягын әйләндергәч, эче яхшырак пешсен өчен, бераз капкач белән каплап пешереп алырга кирәк. Файдалы коймакларны үзен генә дә, гарнир белән дә табынга бирергә, бутерброд өчен дә кулланырга мөмкин.

# ҖИҢЕЛЧӘ КУРКЫТУ ДА ТЫЕЛА

**Курку, шөбһә, борчылу... Ни кызганыч, соңгы арада күңелне күбрәк әнә шул хисләр били. Уяулыкны югалтмаска, үзебезне ничек кенә кулда тотарга тырышсак та, шушы хисләр күзне томалый, күпләрне акылсыз адымнарга да этәрә. Шушы шартларда ничек күңел тынычлыгын сакларга? Курку хисеннән ничек котылырга?**

**«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.**

**:: Исмәгыйль хәзрәт, тынгысыз чорда яшибез. Курку хисе безне даими рәвештә озата бара. Мондый халәт пәйгамбәребез яшәгән чорда да еш күзәтелдеме икән?**

– Курку мәсьәләсендә кешеләрне аңлап була. Соңгы елларда гел киеренке хәлдә яшибез. Башта пандемия чоры куркытты, бүгенге вазгыять тә борчуга сала. Кешеләр сәламәтлеге, якыннары, мал-мөлкәте өчен борчыла. Курку дигәнең сәхабәләр чорында да булган. Әмма бу борчу, куркулар барысы да Аллаһы Тәгаләгә юнәлтелгән. Чын мөселман, курку хисе барлыкка килсә, гөнаһ һәм җинаятькә авышмый, гыйбадәттән ерагаймый, киресенчә, Аллаһка гыйбадәт кылудан, догадан тагын да ныгый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм яшәгән чорда да сугышлар булган. Мәдинә шәһәренә унар меңлек гаскәр килгәч, сәхабәләр дә бик нык курыккан. Әмма шулай да аларның күңелләре төшенке булмаган, алар, киресенчә, берләшкәннәр, күбрәк дога кылганнар, куркуларын Аллаһка юнәлткәннәр, Аннан ярдәм көткәннәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм даими рәвештә дога кылган. Аллаһы Тәгаләдән фәкыйрьлектән, мескенлектән, зәгыйфьлектән, күңел төшенкелегеннән, бурычлардан азат итүне сораган. Ул догалар дини китапларда бар. Аларны укыганда күңел тынычлана. Шул ук вакытта үзенең тискәре фикерләре белән башны бутаучы шайтан да бар. Аллаһы Тәгалә «Коръәни Кәрим»дәге бер аятьтә: «Шайтан сезгә фәкыйрьлек һәм мескенлекне вәгъдә итә. Аларны каршыгызга китереп, сезне җинаять һәм кабахәтлеккә этәрә», – ди. Курку хисеннән товарның бәясен күтәргән, яки, халыкның куркуыннан файдаланып, төрле ялган мәгълүмат тараткан кешеләрне еш күрергә туры килә. Шушы куркуы аркасында үзенә гамәлдәге законнарны үтәмәскә рөхсәт иткән кешеләр дә бар. Шул сәбәпле алар кеше талый, алдаша башлыйлар, Ватаннарыннан качалар. Бу аларның күңелләре Аллаһ белән түгел, шайтан белән булудан, аның коткысына бирелүдән.

**:: Адәм баласы иң беренче чиратта нәрсәләрдән куркырга тиеш? Нәрсәдән, киресенчә, курыкмау хәерле?**

– Динебездә куркыту тыелган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт сәхабәләренең көлгәнен күргән дә: «Сез ни сәбәптән көләсез?» – дип сораган. Алар: «Фәлән дустыбызның камчысыннан булган укларын алдык. Ул шундук эзләнә башлады. Күзләрендә курку күрдек. Бу безгә бик көлке тоелды», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез исә: «Бер мөселман икенче мөселманны куркытырга тиеш түгел», – дигән. Алар аны мәсхәрәләр өчен эшләмәгән, максатлары куркыту булган. Әмма диндә җиңелчә куркыту да тыелган. Без якыннарыбызга, дусларыбызга курку хисләре салырга тиеш түгел. Шулай бервакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер кабиләгә үзенең вәкилен кертеп җибәргән. Алдан: «Әгәр алар безгә хыянәт итсәләр, син миңа моны бер ишарә аша гына әйт. Әгәр алар безнең яклы булсалар һәм килешүләрендә нык булсалар, аны ачыктан-ачык әйт», – дип кисәтеп куйган. Галимнәр пәйгамбәр моны кешеләр арасында курку хисе таралмасын өчен шулай эшләгән дип аңлата. Ник дигәндә, кешене куркыта торган сүзләр куллану безнең динебездә хупланмый. Мөселман кемнән куркырга тиеш соң? Без бу дөньяда берніндән дә курыкмыйбыз. Тәкъвалык, икенче төрле әйткәндә, Аллаһы Тәгаләдән курку дигән төшенчә бар. Ләкин без Аллаһтан бигрәк Аның ачы газабыннан, аның гаделлеге һәм хөкеменнән куркабыз. Кеше бу дөньяда фәкать үзенең гөнаһларыннан, аңа китергән нәфесеннән куркырга тиеш. Аллаһы Тәгалә «Коръәни Кәрим»дә безгә: «Гөнаһларыгыз белән үз-үзегезгә золым китермәгез», – дигән. Ник дигәндә, Кыямәт көнендә, Аллаһ каршына килеп, тормышыбызны инде үзгәртеп булмый. Бу дөньяда бар нәрсә – Аллаһы Тәгалә кулында. Ул гадел, Ул рәхимле вә шәфкатьле.

pixabay.com

**:: Кайберәүләр курку, куркытуны тәрбия чарасы итеп куллана. Баласы сүз тыңласын өчен әйтелгән «әнә фәлән бабай алып китә хәзер», «тегенди, мондый булып каласың» ише куркыту сүзләрен еш ишетергә туры килә. Куркытуны тәрбия чарасы итеп куллануга ничек карыйсыз?**

– Дөрестән дә, без балаларыбызны да кем белән дә булса куркытырга мөмкинбез. Әмма исламда бу да тыела. Баланы куркытырга ярамый. Киресенчә, балага куйган таләпләребезне үтәргә, аннан сорарга, таләп итәргә тиешбез. Баланың күңеленә ни рәвешле ачкыч табарга кирәклеген ике сүз белән генә аңлатып бетереп булмый. Ләкин шунысы аерым ачык – бу эш эзлекле рәвештә алып барылырга тиеш. Син баладан нәрсәдер таләп иткәнсең икән, аның аны үтәгәнме-юкмы икәнлеген дә тикшерергә тиешсең. Куркытуга караганда мең өлеш нәтиҗәлерәк алым бу.

**:: Куркулык кою дигән төшенчә бар. Ислам дине бу күренешкә нинди мөнәсәбәттә?**

– Бу күренеш белән очрашканым бар. Ул – шәригать белән үтәлгән бер эш. Курграш алып, догалар, сүрәләрне укып, кеше өстеннән курку коялар. Моның өчен өшкерү белән шөгыльләнгән кешегә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Һәрбер мулла өшкерү белән шөгыльләнә дигән сүз түгел. Ул дога, сүрә укып җибәрә. Әмма куркулыкны койдыру өчен өшкерүче махсус кешегә барырга кирәк. Ул ислам кануннары белән эш итүче, Коръәнне укый белүче белемле, ихласлыгы белән аерылып торучы кеше булырга тиеш. Ниндидер шикле белдерүләр буенча куркулык койдыручыга бару тыела.

**:: Куркуга ничек бирелмәскә?**

– Моның өчен, иң беренче чиратта, иманыбыз өстендә эшләргә кирәк. Аңа башка борчу, курку төшкәнче үк тотынасы. Күреп торабыз: аз гына борчулы хәбәр ишеттеме, кеше, кибеткә чабып, кирәксә-кирәкмәсә, күпләп әйбер җыя башлый. Шуннан үзеннән-үзе ажиотаж барлыкка килә. Моңа һаман да шул курку сәбәпче. Динебез буенча, мөселманның өендә ризык ягыннан һәрчак запас булырга тиеш. Курку хисеннән котылу өчен без, Коръән тыңлап, зекер кылып, дога укырга тиешбез. Ник дигәндә, дәүләт мәсьәләсендә булган эшләргә берничек тә тәэсир итеп булмый. Без бу очракта күңел тынычлыгы гына саклый алабыз. Көндәлек эшләребез белән шөгыльләнергә кирәк. Күңел төшереп, кулларны салындырып утырсак та, бу мәшәкатьләр узып китәчәк, билгеле. Әмма үз эшләребез башкарылмый калачак. Әйтик, тиздән рамазан ае якынлаша. Без күңелебезне, сәламәтлегебезне аңа әзерләдекме? Шушы көндәлек эшләрне дә хәл итәргә кирәк, куркып, кул кушырып утырып кына булмый. Догада булсак, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламас, авырлыклар узып китәчәк.

## Уенчыклар

Бервакыт бер авылга зирәк карт килгән һәм шушы авылда төпләнеп калган. Ул бик балалар яраткан һәм күп вакытын алар белән үткәрә торган булган. Ул балаларга бүләкләр бирергә дә бик яраткан, ләкин ул аларга тиз ватылучан әйберләр бүләк итә икән. Балаларның моңа бик кәефләре төшкән һәм алар бик нык елаганнар. Күпмедер вакыт үткәннән соң зирәк карт аларга тагын уенчыклар бүләк иткән, ләкин болары исә тагын да тизрәк ватыла торган булганнар.

Балаларның әти-әниләре бу хәлгә түзеп тора алмаганнар һәм бу карт янына килгәннәр. Алар бу зирәк картка: «Син үзең зирәк һәм акыллы, безнең балаларга бары тик яхшылык кына телисең. Ләкин ни өчен син аларга шундый бүләкләр бирәсең? Ул уенчыкларны никадәр сакларга тырышсалар да, алар барыбер ватылалар һәм балаларыбыз моңа бик борчылып елашалар. Син бүләк иткән уенчыклар шундый матурлар, алар белән уйнамыйча мөмкин дә түгел», – дип әйтәләр.



Зирәк карт елмаеп, хикмәт белән: «Озак вакыт үтмәс, кемдер аларга үзенең йөрәген бүләк итәр. Бәлки бу аларны шул кыйммәтле бүләк белән азрак кына саграк булырга өйрәтер», – дип җавап кайтарган.

**Йәгез, бер дога!**

### Курыкканда укыла



«Хәсбүнә-Ллааһу үә нигъмәл-үәкииил».

**Мәгънәсе:** «Аллаһ безгә җитә, Ул [бөтен эшләр тапшырыла торган] нинди яхшы Яклаучы!»

(«Әлү-Гыймран» сүрәсе, 173 нче аятьтән өзек)

**Хәдис**

Бернинди нигезсез кешеләр турында яман уйлаудан саклангыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң ялганы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһының коллары булган хәлдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз!

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

# КӨРӘШЧЕ РЕНАС КӘЛИМУЛЛИН:

# «БАБАМНЫҢ СҮЗЛӘРЕНӘ ТУГРЫ КАЛЫП БИЛ АЛЫШАМ»

**Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенең кунагы – иң титуллы көрәшчеләрнең берсе. Дөнья чемпионатын – дүрт, Татарстан һәм Россия чемпионатларын һәм «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган, герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирын алтышар мәртәбә откан егет ул. Сүзебез Ренас КӘЛИМУЛЛИН турында.**

**:: Ренас, җиңүләрегез хәйран күп. Әле без иң-иңнәрен генә санадык. Титулларның күп булуы көрәшергә ярдәм итәме?**

– Дөресен генә әйткәндә, ике яклы мәсьәлә бу. Бер яктан, көндәшең келәмгә синнән куркып, әмма бик нык әзерләнеп чыга. Җиңүләрнең күп булуы бик зур җаваплылык та өсти. «Бу турнирда да сынатмаска кирәк» дигән уй белән көрәшәсең. Келәмгә аяк басканда ук, алдагы җиңүләрне акларга кирәк, дип чыгасың.

> Бер өлкәдә лидер булган кеше тормышының башка өлкәләрендә дә җиңүче булырга тиеш, дип уйлыйм мин.

**:: Җиңелүләрне ничек кабул итәсез?**

– Әле бит җиңеп торам, Аллага шөкер. Җиңелсәм, шактый авыр булыр, дип уйлыйм.

**:: Гомумән, көрәш популярмы бүген?**

– Башка спорт төрләре белән чагыштырып карасаң, бик популяр түгел. Җанатарлар бар әле, билгеле. Турнирларга махсус мине карар өчен дә йөрүчеләр бар.

**:: 15 еллап көрәшәсез дип беләм. Элек белән хәзерне чагыштырырлык тәҗрибә бар кебек...**

– Әле дә исемдә: элек Муса Җәлил истәлегенә көрәш турниры Чаллыда уза иде, беренче тапкыр көрәш карарга нәкъ шунда бардым. Алма төшәрлек урын да юк, халык бирелеп бил алышканнарын карый. Шунда «Бу турнирда җиңү бик авырдыр инде, ә җиңсәң, атаклы көрәшче буласыңдыр» дип уйлап куйганымны хәтерлим.

Сабантуйларны алсак, анда инде элек-электән районга карап җыела иде кеше. Кайбер районнарда көрәшне бик яраталар, кайберләрендә ни икәнен дә белмиләр. Ерак китәсе юк: үзем туып-үскән Менделеев районында көрәш популяр түгел. Гомумән, оста спортчылар юк диярлек. Хәзер мин Теләче өчен көрәшәм – монда хәл башкачарак. Көрәшчеләр дә җитәрлек, бил алышканнарын яратып караучылар да. Кайбер авылларга барасың, өлкән яшьтәге бабайлар да хәтта төнгә кадәр көрәш карый.

**:: Теләче өчен көрәшә башлавыгызның сәбәбе туган районыгызның көрәшкә карата мөнәсәбәте идеме?**

– Өлешчә. Башка районга күчену турында уйлана башлагач, район башлыгы янына кердем. Сөйләштек. Өмет юклыгын аңлагач, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде. Кирәк булсам, җаен табып, йә җибәрмәсләр, йә кире чакырырлар иде.

**:: Безнең газета гамәлгә куйган көрәш турниры турында сөйләшә башлаган идек инде. Аңа сез балачакта ук бәя биреп куйгансыз. Ул бәя үзгәрмәдеме?**

– Юк. Гомумән, шәхсән үзем өчен әлеге турнир әһәмияте буенча Татарстан чемпионатыннан гына калыша, дип уйлыйм. Аны оту җиңелләрдән түгел. Чит төбәкләрдән килгән спортчылар белән дә танышырга, бил алышырга мөмкинлек бар.

**Блиц-сораштыру**

**– Көрәшче булмасагыз, нинди һөнәр сайлар идегез?**

– Белмим, тормышымны келәмнән башка күз алдына китерә алмыйм.

**– Ярыш алдыннан, менә моны эшләргә кирәк яисә ярамый, дигән берәр ышануыгыз юкмы?**

– Юк кебек. Аякка яңа «борцовка» кигән чакта, моның белән җиңә алырмынмы икән, дигән уйлар килгәли.

**– Яраткан ризыгыгыз?**

– Бар нәрсәне ашыйм мин, итле генә булсын.

**– Яшь көрәшчеләргә киңәшегез.**

– Җиңә алмасалар да, көрәшне ташламасыннар. Вакыты гына җитмәгән булырга мөмкин. Яшьли отмасаң да, зурлар арасында җиңү ихтималы бар.

**:: Шулай да алты мәртәбә откансыз. Беренче тапкыр җиңгәндә ниләр кичергәнегез исегездәме?**

– Беренче тапкыр Зәй келәмендә батыр калдым. Илмир Тәхвәтуллинны оттым ул чакта. Җиңел булмады, чөнки көчләр тигез диярлек иде. Ә җиңгәч, икеләтә сөендем.

**:: Быелгы турнирга ниятләрегез нинди?**

– Җиңәргә дип киләм инде.

**:: Көрәшкәндә, сезнең өчен нәрсә мөһим?**

– Минем беренче тренерым һәм киңәшчем бабам иде. Ул миңа гел: «Син көндәшләреңнән бер баш югары булырга тиеш», – дия килде. Шул сүзләр йогынты ясагандыр инде: бер генә балл аерма белән оту җиңү түгел инде. Чистага, матур алымнар күрсәтеп отарга кирәк. Җиңү булса, шундый булсын. Бабамның сүзләренә тугры калып көрәшәм.

**:: Сезнең үз гаиләгез дә бар бит әле. Тормыш иптәшегезнең, көрәшмә, дигәне булмадымы?**

– Юк, ул үзе дә бик яратып карый көрәшне, кызым да читтә калмый. Һәр хатын-кыз үз ирен, нинди генә өлкәдә эшләсә дә, җиңүче итеп күрергә тели, миңа калса. Үземнең һәм хатынымның әти-әнисе дә, ә алар Ижауда яши, мин катнашкан ярышларның барысын да килеп карыйлар. Терәгең, таянычың булу – бик мөһим.

**:: Үз киявегез дә көрәшче булса...**

– Каршы килмәс идем.

# Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

***Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.***

Әлеге җырны башкаручы бер гамәлең аркасында «аны, мине, үзеңне дә бәхетсез итәсең» дип уйлый.

Бу җыр исә иң кадерле кешеләребезгә багышлана. Тиз генә кайтып килүебез өчен рәнҗеп калмаска куша җырчы.

Әлеге рәсемнәр астына яшерелгән җыр соңлап килгән газиз ярга багышлана. Үпкәләсә үпкәли, әмма хәсрәт кенә китермәсен, ди җырчы.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

## 16 март | Чәршәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Калеб» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00, 23.50 «Соотечественники» 12+
00.15 «Вехи истории». Они поднимали страну 12+
00.40 «Җырлыйк әле!» 6+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Гамил Әсхадулла турында телеочерк 6+

### 1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЯНЫЧАР». Многосерийный фильм (S) 16+
23.25 «Большая игра» 16+
00.25 «Сергей Юрский. Против правил» 12+
01.30 «Время покажет» 16+
03.00 Новости
03.05 «Время покажет» 16+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.00 Вести
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.00 Вести
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.00 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
03.40 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соковский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 08.30, 12.25, 14.50, 17.50 Новости
06.05, 22.25, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Биатлон. Кубок России. Финал. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Уфы
10.20, 13.30, 03.50 Специальный репортаж 12+
10.40 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
11.05 Биатлон. Кубок России. Финал. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Уфы
12.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.50, 14.55 «ПРАВИЛА ОХОТЫ. ШТУРМ» 16+
17.55 «13 УБИЙЦ» 16+
20.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Майнц» – «Боруссия» (Дортмунд). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Ювентус» (Италия) – «Вильярреал» (Испания). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Лилль» (Франция) – «Челси» (Англия) 0+
03.45 Новости 0+
04.05 «Несвободное падение. Инга Артамонова» 12+
05.05 «Одержимые. Ольга Брусникина» 12+
05.30 «Голевая неделя РФ» 0+

### НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.40 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Дворняга» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «САШКА» 16+
19.00 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+
23.15 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 45-я и 46-я серии 16+
01.10 «Эффект Матроны» 16+
06.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ХУТОРЯНИН» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15, 01.25 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.35 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05, 03.50 «ХУТОРЯНИН» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Док. сериал. «Города-крепости» 16+
19.40 «Главный день». «Автомат Калашникова». Премьера! 16+
20.25 «Секретные материалы». Док. сериал. Премьера! 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ЛАРЕЦ МАРИИ МЕДИЧИ» 12+
03.05 «Тамерлан. Архитектор степей». Док. фильм 12+

## 17 март | Пәнҗешәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00, 00.00 «ЛЮБОВЬ ПО ПРИКАЗУ» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 12+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». Мирсаит Султан-Галеев. Отец революции третьего мира 12+
01.40 «Вехи истории». Большая нефть Татарии 16+
02.05 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
15.30 «Халкым минем» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Калеб» 6+

### 1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.30, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЯНЫЧАР» (S) 16+
23.25 «Большая игра» 16+
00.25 «Григорий Горин. «Живите долго!» 12+
03.00 Новости

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
02.00 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
03.40 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.25, 14.50, 20.25 Новости
06.05, 19.15, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 «ПРАВИЛА ОХОТЫ. ОТСТУПНИК» 16+
12.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30, 03.50 Специальный репортаж 12+
13.50, 14.55 «ПОЕДИНОК» 16+
15.50 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Грега Харди. Трансляция из Москвы 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции «Восток». Прямая трансляция
20.00 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
20.30 Футбол. Лига Европы. 1/8 финала. «Галатасарай» (Турция) – «Барселона» (Испания). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига Европы. 1/8 финала. «Вест Хэм» (Англия) – «Севилья» (Испания). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига Европы. 1/8 финала. «Байер» (Германия) – «Аталанта» (Италия) 0+
03.45 Новости 0+
04.05 «Несвободное падение. Александр Белов» 12+
05.05 «Одержимые. Ирина Слуцкая» 12+
05.30 «Третий тайм» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.20 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ» (S) 16+
23.40 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.20 «Поздняков» (S) 16+
00.35 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.30 «ПЁС» (S) 16+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Рыбаки» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «КОГДА УМРЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ» 16+
23.05 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 47-я и 48-я серии 16+
00.55 «Эффект Матроны» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «ХУТОРЯНИН» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.15 «СЛЕД СОКОЛА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.35 «Оружие Победы» 12+
13.50, 14.05 «ПРАВО НА ПОМИЛОВАНИЕ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». «Калинин» 16+
19.40 «Легенды кино». Премьера! 12+
20.25 «Код доступа». Премьера! 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
01.35 «ТЫ – МНЕ, Я – ТЕБЕ» 12+
03.00 «Россия и Китай. «Путь через века». Док. фильм 6+
03.25 «Западная Сахара. Несуществующая страна». Док. фильм 12+
03.55 «Москва фронту». Док. сериал 16+
04.20 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+

## 18 март | Җомга

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Насыйхәт» 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Мин» 12+
18.00 «Родная земля» 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.00 «Соотечественники». Сахибгарай Саид-Галеев. Президент «Звезды Востока» 12+
00.25 «Вехи истории». Татарская культура. Душа народа 12+
00.50 «КИТӘМ, ДИМӘ...» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30 «Насыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.10 «Туган җир» 12+
20.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Гамил Әсхадулла турында телеочерк 6+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
01.05 Эдуардо де Филиппо. «ГАУГАЛЫ ГАИЛӘ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 0+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.30 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.30 «Голос. Дети». Новый сезон (S) 0+
23.05 «Большая игра» 16+
00.05 Док. фильм «Джоди Фостер: Строптивое дитя» (S) 16+
01.15 «Наедине со всеми» 16+
02.00 «Модный приговор» 0+
02.50 «Давай поженимся!» 16+
04.50 «Россия от края до края» 12+

### РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Александр Устюгов, Дарья Урсуляк, Илья Ильиных, Мария Андреева, Андрей Мерзликин, Александр Горбатов, Ирина Пегова, Евгений Ткачук. «ГОДУНОВ. ПРОДОЛЖЕНИЕ» 16+
01.50 Олеся Фаттахова, Евгений Шириков, Агата Муцениеце, Кирилл Запорожский, Наталья Чернявская. «МЕЛОДИЯ НА ДВА ГОЛОСА» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00, 08.30, 12.25, 14.50 Новости
06.05, 19.15, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 «ПРАВИЛА ОХОТЫ. ШТУРМ» 16+
12.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.30, 03.50 Специальный репортаж 12+
13.50, 14.55 «13 УБИЙЦ» 16+
16.25 Футбол. Еврокубки. Обзор 0+
16.55 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции «Восток». Прямая трансляция
19.25 Хоккей. КХЛ. 1/2 финала конференции. Прямая трансляция
22.35 «Точная ставка» 16+
22.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Барселона» (Испания) – «Црвена Звезда» (Сербия). Прямая трансляция
01.55 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Париматч». Мужчины. «Зенит-Казань» – «Кузбасс» (Кемерово) 0+
03.45 Новости 0+
04.05 «Несвободное падение. Валерий Воронин» 12+
05.05 «РецепТура» 0+
05.30 «Всё о главном» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
09.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» (S) 16+
17.55 «Жди меня» (S) 12+
20.00 Следствие вели... (S) 16+
21.00 Премьера. «Страна талантов» (S) 12+
23.40 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.30 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
01.55 Квартирный вопрос (S) 0+
02.50 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Око» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ХОЧУ ТЕБЕ ВЕРИТЬ» 16+
19.00 «ПРИСЯЖНАЯ» 16+
23.20 «Про здоровье» 16+
23.40 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 2». 49-я и 50-я серии 16+
01.35 «Эффект Матроны» 16+
05.55 «Пять ужинов» 16+
06.10 «Предсказания: 2022» 16+

### ЗВЕЗДА

05.45 «НЕ ЗАБЫВАЙ» 16+
07.45, 09.20 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
11.10, 13.25, 14.05 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.40, 18.40, 21.25 «ЭШЕЛОН» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.10 «Десять фотографий» 12+
00.05 «СЛЕД СОКОЛА» 12+
02.05 «ЛИХА БЕДА НАЧАЛО» 12+
03.15 «ТЫ – МНЕ, Я – ТЕБЕ» 12+
04.40 «Москва фронту». Док. сериал 16+

## 19 март | Шимбә

### ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Мин» 12+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Созвездие – Йолдызлык-2022» 6+
14.30 «Юлчы» 6+
15.00 «Дусларыма – җырларым». Вәис Бәйрәмов концерты 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
17.00 «СТЭНДАПханә» 16+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
21.30 Новости в субботу 12+
22.00 «КунакБиТ шоу» 12+
23.00 «МИЛЛИОН В БРАЧНОЙ КОРЗИНЕ» 12+
00.30 «Каравай». Первый исследователь 6+
01.00 «КИТӘМ, ДИМӘ...» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Бөркет канатында хөрлек бар». Язучы Адлер Тимергалин турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Көлке чыбыркысы». Түбән Кама «Мунча ташы» эстрада театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе 6+
23.10 Н.Исәнбәт. «ГӨЛҖАМАЛ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
01.30 «Китмә, сандугач». Илһам Шакиров ядкәре 6+
03.00 «Башваткыч» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+

### 1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Амурский тигр. Хозяин тайги» 16+
11.15 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.00 Балет на льду Татьяны Навки «Лебединое озеро» (S) 0+
15.45 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
17.20 Премьера. «Наша Надя» (S) 16+
19.20 Премьера. 45 лет ансамблю «Русская песня» (S) 12+
21.00 «Время»
21.20 Виктория Исакова. «ОДИН ВДОХ» (S) 12+
23.15 Премьера. История Жак-Ива Кусто. Ламбер Вильсон. «ОДИССЕЯ» (S) 16+
01.30 «Наедине со всеми» 16+
02.15 «Модный приговор» 0+
03.05 «Давай поженимся!» 16+
03.45 «Мужское/Женское» 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 Любовь Баханкова, Михаил Пшеничный. «МОЙ ЧУЖОЙ РЕБЕНОК» 12+
13.30 Карина Разумовская, Елена Подкаминская, Татьяна Казючиц, Павел Трубинер, Нелли Пшенная, Виталий Егоров. «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ» 12+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести в субботу
21.00 Премьера. Елена Аросьева, Дмитрий Пчела, Екатерина Рябова, Антон Денисенко, Екатерина Копанова, Александр Давыдов, Владислав Канопка, Леонид Громов, Илья Соколовский. «ПРОСТИ ЗА ЛЮБОВЬ» 12+
01.05 «НЕ ЖАЛЕЮ, НЕ ЗОВУ, НЕ ПЛАЧУ» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Джамал Джеймс против Раджаба Бутаева. Трансляция из США 16+
07.00, 09.00, 13.25 Новости
07.05, 13.30, 16.00, 22.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «ГОНКА» 16+
11.30 «ПОЕДИНОК» 16+
13.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Нижний Новгород» – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
16.25 Смешанные единоборства. UFC. Лучшие бои Александра Волкова 16+
17.55 Формула-1. Гран-при Бахрейна. Квалификация. Прямая трансляция
19.05 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Арсенал» (Тула). Прямая трансляция
21.30 Футбол. Прямая трансляция
23.00 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Тома Аспинэлла. Прямая трансляция из Великобритании
01.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Интер» – «Фиорентина» 0+
03.45 «Реал» Мадрид. Кубок №12». Док. фильм 12+
05.30 «Тот самый бой. Руслан Проводников» 12+

### НТВ

04.55 «ЧП. Расследование» (S) 16+
05.25 Эдуард Флёров. «ДВЕНАДЦАТЬ ЧАСОВ» (S) 16+
07.20 Смотр (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «Готовим» (S) 0+
08.50 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 Едим дома (S) 0+
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
13.05 «Однажды...» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00 Следствие вели… 16+
16.20 Следствие вели… 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 Ты не поверишь! (S) 16+
21.20 «Секрет на миллион». «Мамы звезд» (S) 16+
23.30 «Международная пилорама» (S) 16+
00.25 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Концерт ко Дню Рождения Александра Зарецкого (S) 16+
01.40 «Дачный ответ» (S) 0+
02.30 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
07.05 «ДРУГАЯ ЖЕНЩИНА» 16+
10.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 41-я и 42-я серии 16+
23.20 «Скажи, подруга» 16+
23.35 «РАДУГА В НЕБЕ» 16+
03.10 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ». 1-я – 3-я серии 16+
05.55 «Предсказания: 2022» 16+

### ЗВЕЗДА

05.00 «САМЫЙ СИЛЬНЫЙ» 6+
06.25, 08.15 «КОМАНДИР СЧАСТЛИВОЙ «ЩУКИ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.40 «Морской бой». Премьера! 6+
09.45 «Круиз-контроль». «Салехард – Минлей» 12+
10.15 «Легенды музыки». Надежда Бабкина 12+
10.45 «Улика из прошлого». «Тайнопись будущего. Библейский код» 16+
11.35 «Война миров». Док. сериал. «Конница против танков» 16+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
14.05 «Подводный флот России». Док. сериал 16+
17.20, 18.30 «СЛУШАТЬ В ОТСЕКАХ» 12+
18.15 «Задело!» 16+
20.45 «Легендарные матчи». «Волейбол. Женский. Финал Олимпиады-1988. СССР – Перу – 3:2» 12+
00.15 «СЕКРЕТНЫЙ ФАРВАТЕР» 12+
04.50 «Полководцы России. От Древней Руси до XX века». Док. сериал. Рокоссовский 12+
05.30 «Москва фронту». Док. сериал 16+

## 20 март | Якшәмбе

### ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 Нәфкать Нигъмәтуллин концерты 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «ХАЙКЮ». Мультфильм 12+
09.00 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык» 12+
11.00 Илсөя Бәдретдинова концерты 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 «Созвездие – Йолдызлык-2022» 6+
14.30 «Дания Нуруллинаның юбилей кичәсе» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 12+
20.00 «Ватандашлар» 16+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
23.00 «ГОЛОГРАММА ДЛЯ КОРОЛЯ» 18+
01.00 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00, 16.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
08.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Мәсгудә Шәмсетдинова турында телеочерк (субтитрлы) 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Татарлар» 12+
13.35 «Нәсыйхәт» 6+
14.05 «Олы юл әйтте...» циклыннан. Үткәннәрне барлап...» Айдар Фәйзрахманов. Туган көнне каршылап 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Айлы кичтә». Энҗе Шәймордина концерты 6+
23.20 «Халкым минем» 12+
23.45 «Ком сәгате» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
01.05 «Манзара» 6+

### 1 КАНАЛ

05.20, 06.10 Александр Михайлов. «ВОПРЕКИ ВСЕМУ» 12+
06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.15 «Видели видео?» 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.05 «Суровое море России» 12+
15.55 Ко дню рождения Александра Вертинского. «Жил я шумно и весело» 16+
17.05 «Док-ток». «Доченьки» 16+
18.00 «Вертинский. Песни» (S) 16+
19.05 Премьера. «Две звезды. Отцы и дети». Финал (S) 12+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. Юлия Пересильд, Константин Хабенский, Виктория Исакова. «ТРОЕ» (S) 16+
00.20 К 100-летию со дня рождения Ирины Антоновой. «Я давно иду по прямой» 12+
01.20 «Наедине со всеми» 16+
02.05 «Модный приговор» 0+
02.55 «Давай поженимся!» 16+

### РОССИЯ 1

05.20 Дарья Егорова, Александр Пашков, Илья Оболонков. «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «РАБОТА НАД ОШИБКАМИ» 12+
13.40 Карина Разумовская, Елена Подкаминская, Татьяна Казючиц, Павел Трубинер, Нелли Пшенная, Виталий Егоров. «ТОЛЬКО О ЛЮБВИ» 12+
17.50 Премьера. «Танцы со Звёздами». Новый сезон 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 «ЛЮБОВЬ НА СЕНЕ» 12+
03.15 «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Мэнни Пакьяо против Йордениса Угаса. Трансляция из США 16+
07.00, 09.00, 12.55, 17.35 Новости
07.05, 13.00, 22.00, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «СПОРТ ТОША» 0+
09.40 Смешанные единоборства. UFC. Александр Волков против Тома Аспинэлла. Трансляция из Великобритании 16+
10.55 Баскетбол. Чемпионат России. Женщины. УГМК (Екатеринбург) – «Динамо» (Курск). Прямая трансляция
13.30 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. ЦСКА – «Рубин» (Казань). Прямая трансляция
15.55 Гандбол. Чемпионат России «Олимпбет-Суперлига». Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Лада» (Тольятти). Прямая трансляция
17.45 Формула-1. Гран-при Бахрейна. Прямая трансляция
19.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Динамо» (Москва) – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Болонья» – «Аталанта». Прямая трансляция
01.45 Мини-футбол. Кубок России. «Финал 4-х». Финал. Трансляция из Тюмени 0+
03.40 Формула-1. Гран-при Бахрейна 0+
05.30 «Тот самый бой. Мурат Гассиев» 12+

### НТВ

04.45 «ЗОЛОТОЙ ТРАНЗИТ» (S) 16+
06.35 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 Своя игра (S) 0+
15.00, 16.20 Следствие вели… 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели»
20.10 «Маска». Новый сезон (S) 12+
23.20 «Звезды сошлись» (S) 16+
00.50 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
03.25 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА» 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2022» 16+
06.45 «ЧАСЫ С КУКУШКОЙ» 16+
10.30 «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ» 16+
14.30 «ПРИСЯЖНАЯ» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК». 43-я и 44-я серии 16+
23.25 «Про здоровье» 16+
23.45 «РЕФЕРЕНТ» 16+
03.15 «ГОРДОСТЬ И ПРЕДУБЕЖДЕНИЕ» 16+
05.45 «Пять ужинов» 16+
05.55 «Предсказания: 2022» 16+

### ЗВЕЗДА

06.00 «Оружие Победы» 12+
06.10 «СЛУШАТЬ В ОТСЕКАХ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №92» 16+
11.30 «Секретные материалы». Док. сериал. «Михаил Лукин. Судьба генерала» 16+
12.20 «Код доступа» 12+
13.15 «Специальный репортаж» 16+
13.55 «НА БЕЗЫМЯННОЙ ВЫСОТЕ» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.20 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.45 «Сделано в СССР» 12+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «К-3. «Ленинский комсомол». Док. фильм 12+
01.05 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
02.25 «Ангелы с моря». Док. фильм 12+
03.10 «Москва фронту» 16+
03.35 «НА БЕЗЫМЯННОЙ ВЫСОТЕ» 16+

---

РАДИО РОССИИ

**«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?**

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

### Дүшәмбе, 14 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Рәфкать Кәрами. «Каргышлы этаплар». Радиоспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

### Сишәмбе, 15 март

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Рәшит Ваһапов язмалары

### Чәршәмбе, 16 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 «Саз» ансамбле чыгышы

### Пәнҗешәмбе, 17 март

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Әкрәм Даутов җырлары

### Җомга, 18 март

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Ришат Төхвәтуллин җырлый

### Шимбә, 19 март

8.10 «Саумы, сөюем, саумы, язмыш!» Рәдиф Гаташ әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Татар халык җырлары
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Уильям Шекспир. «Отелло». Радиотамаша. 1 нче өлеш

### Якшәмбе, 20 март

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35, 16.10 Уильям Шекспир. «Отелло». Радиотамаша. 2-3 нче өлеш

---

# ЕРЫК АВЫЗ

**Авырып киткән физкультура укытучысын хезмәт укытучысы алмаштыра:**

**– Балалар, барыгыз, чаңгылар алып керегез. Бүген без сезнең белән алардан табуреткалар ясыйбыз.**

***

Кеше гомеренең 30 проценты йоклап, 70 проценты йокы туйдыру турында хыялланып уза.

***

**Хатын-кызлар – безнең йомшаклык. Балалар – безнең шатлык. Бер тапкыр йомшаклык күрсәтсәң, гомер буе шатланасың.**

***

Суд бара.

– Нигә 20 ел бергә яшәгән иреегездән аерылырга булдыгыз?

– Сезнеңчә, 20 ел бик азмы ул?!

***

**– Мин хатыныма бриллиант ташлы йөзек бүләк иттем. Хәзер инде ике атна ул минем белән сөйләшми.**

**– Нишләп?**

**– Шундый шарт куелган иде чөнки.**

# ВАТАН ХАКЫНА

## ПАТРИОТНЫ НИЧЕК ҮСТЕРЕРГӘ?

**Замана балалары, кока-кола эчмичә, «Макдоналдс» ризыклары ашамыйча, «ТикТок» карамыйча, айфонсыз ничек яшәрмен, дип борчыла башлады. Шул ук вакытта «туган ил», «авыл», «әти-әни кадере» төшенчәләре икенче урынга калып бара кебек. Күбрәк үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртырга өйрәнгән яшьләргә яңа тормышка ияләшү авыр булмасмы? Аларда ватанпәрвәрлек хисен ничек тәрбияләргә?**

Илдар Мөхәммәтҗанов

### Мохит үзгәртә

Балтач районының Әфганчы ветераннар советы җитәкчесе, Әфган, Чечня сугышларында катнашкан Дилүс Гатиатуллин – балаларга, ә балалар аңа аптырый. Ул музейда дәресләр бирә, үсмерләрне йөзәргә өйрәтә. Бассейнга телефон тотып килгән балалар: «Абый, әллә сездә «ТикТок» юкмы?» – дип гаҗәпләнәләр икән. Тренер абыйларыңа, ул үскәндә, мондый нәрсәләр булмаганны аңлатырга туры килә.

– Яшьләрнең дөньяга карашлары да, таләпләре дә икенче. Без – коммунистлар идеологиясе белән тәрбияләнгән буын. Ә замана баласы көнбагыш чиртергә ияләнмәгән, аларга чипсы кирәк. Чипсы түгел, бәрәңге ашагыз, аннан да тәмлерәк әйбер юк, дим. Яшьләргә яңа шартларга ияләшү бик авыр булачак, дип уйлыйм. Аларның кулында туганнан бирле телефон бит. Ярый әле аны бассейнга тотып кермисез, дип шаяртам, – ди Дилүс әфәнде.

Мәктәпләрдә укучыларны хәрби әзерлеккә өйрәтү туктатылгач, күңелендәге хыялын тормышка ашырган – музей оештырган ул. «Бөек Ватан сугышы тарихын укучылар бик начар белә. Әлеге сугышны белмәүчеләргә Әфганстан турында сөйләү тагын да авыр. Батырлык үрнәкләре турында сөйләп, илгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләргә тырышам. Укытучылар да музейга күбрәк фотога төшү, мәктәптә хисап тоту өчен килә. Игътибар белән тыңлаган балалар бар, тик күзләрендә очкын уйнап торганнары аз. Граната, мылтык, фляганы тотып карыйлар. Укуны әзмәс өчен, музейга баруны соңгы сәгатькә куялар. Шуңа күрә укучылар арып килә, тыңларга теләкләре бик калмый. Патриотик рух юк, мәктәпләрдә яхшы итеп аңлатсалар, булыр иде ул. Балалар каһарманнарны белергә тиеш», – ди Дилүс Гатиатуллин.

Татарстанның халык укытучысы, Биектау районындагы Дөбъяз мәктәбенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Радик Җиһаншин, балаларда ватанпәрвәрлек хисе юк, дигән фикер белән килешми.

– Төрле кешедә төрлечә ул. Укучыларның яртысыннан артыгы – яхшы гына патриотлар. Ватанпәрвәрлек хисен тәрбияләү мәктәптән генә түгел, гаиләдән, әти-әниләрдән, мохиттән дә тора. Яшьләр начар дип сүгәләр, әйбәт алар. Шундый шартларда үскәнгә алар гаепле түгел бит. Шуңа яраклашырга туры килә. Тирәлек үзгәреп тора, элек башка иде, хәзер икенче төрле. Балаларга юнәлеш бирергә кирәк. Армиягә бару-бармау мәсьәләсендә күбрәк әти-әниләр тәэсир итә. Кечкенәдән үк, хәрби хезмәткә бармыйсың, дип тәрбиялиләр. Шулай итеп, курку хисе туа. Белмәгән әйбер куркыта бит ул. Без укучыларны Танк училищесына алып барабыз. Анда баргач, бөтенләй башкача фикер йөртә башлыйлар. Хәрби частьларга алып барырга, ярышларны күрсәтергә кирәк, – ди Радик әфәнде.

### Туган илне ярату

Яшь буында патриотлык хисе тәрбияләү турында «Юнармия» хәрәкәте башлыгы Александр Бородин белән дә сөйләштек.

– Туган илне яратырга кирәк. Ә ничек? Моның өчен тарихны, әби-бабайларның үткәнен, Бөек Ватан сугышының этапларын, геройларны белергә кирәк. Шуңа нигезләнеп, малайларда ватанпәрвәрлек хисе уяна. Бездә «Юнармия» хәрәкәте үз эченә 33 мең кешене ала. 1194 отряд, 1194 мәктәп шушы мәсьәләләр буенча шөгыльләнә. Мәгариф министрлыгы белән «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз», «Солдатка хат» дигән акцияләр үткәрәбез. Донецк, Луганскидан килгән балалар белән аралашабыз. Мәктәпне тәмамлаганда патриот булып, алар үз Ватанын яратачак, – ди Александр Бородин.

Казанда яшәүче отставкадагы полковник, 94 яшьлек Александр Шахназаров ватанпәрвәрлек хисен бары үрнәк күрсәтеп кенә тәрбияләп була дип саный.

–Без узган гасырның 30 нчы елларында тәрбияләндек. Ул елларда кызыклы әйберләр шактый булды. Стахановчыларга, бозваткычларга шаккатып карый идек. Мәктәп, техникум да патриотлык хисен ныгытуга үз өлешен кертте. Аннан сугыш башланды, хәрби дәресләр бирделәр. 33 ел хәрби булдым, – ди сугыш ветераны. – Мин атна саен 4–5 газета белән танышып барсам да, хәзерге мәктәп, вуз системасыннан ерак. Элек Суворов училищесына очрашуларга еш бара идем. Әлбәттә, уку йортларыннан да күп нәрсә тора. Волонтерлар килеп, хәлемне белешә. Сөйләгәнемне тыңлап, төрле сораулар бирәләр. Бу да – ватанпәрвәрлек! Ничек кенә әле!

### «Ватанымны бернигә дә алыштырмыйм»

Көн саен тарих турында, без бөек, дип сөйләп торудан файда юк. Үз туган җирендә яхшы шартлар тудырырга кирәк, шул очракта һәркем үзен бәхетле хис итәчәк. Әгәр кеше хәерчелектә, җимереклектә яшәсә, бу җир никадәр матур, яхшы дисәң дә, туган илгә карата мәхәббәт уянмаячак, аның өчен көрәшү теләге тумаячак. Казандагы Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов исемендәге кадетлар мәктәп-интернат директоры Рәис Юнысов шулай ди.

– Илне яратыгыз дип кенә мәхәббәт тумаячак. Үз җырларыбызны, тарихыбызны күпме генә яратсак та, матди хәлебез бар нәрсәнең нигезе булып тора. Әгәр мәхәббәт уянып та, игътибар җитмәсә, ул юкка чыгачак. Патриотлык хисе белән дә шулай. Үз өен, җирен, андагы кешеләрне яратучылар авыр чакта соңгы икмәген башкалар белән бүлешәчәк, – ди Рәис Юнысов. – Бу яхшы, ә бу начар, дип кенә сөйләү нәтиҗә бирми. Дөресен сөйләргә һәм вакыйгага үз мөнәсәбәтеңне белдерергә кирәк. Без көн саен дәресләрдән соң «үз-үзеңне әзерләү» сәгатьләре уздырабыз. Көн кадагында булган җитди темаларны алып, белгечләрне чакырып сөйләшәбез. Яшьләрне телефонда утыра, гамьсез дип сүгәргә кирәкми. Кечкенә чакта безне дә әбиләр, телевизор төбеннән китмисез, дип ачулана иде. Беребез дә начар булып үсмәдек.

Рәис Юнысов әйтүенчә, чит илдәге шартларга кызыгу, читтән күзаллау – бер, ә андагы вазгыятьне күрү – икенче нәрсә. Читтә безгә бар да ал да гөл кебек тоела. «Хәрби хезмәттә булган дусларым төрле илләрдә яши. Шуларның берсе ел саен Россиягә кунакка кайта. Беренче булып, нишли дип уйлыйсыз? Мәскәүгә кайтып, яшәү урыны буенча беркетелгән сырхауханәгә барып, сәламәтлеген тикшертә, тешләрен куйдырта. Ел буена җитәрлек дару сатып ала. Бездә арзан, анда исә хәтта табибка әләгү дә бик кыйммәт. Акчаң, эшең булса гына яшәү рәхәт. Башка илдә, башка шартларда яши алмыйм. Кая гына барсам да, тизрәк өйгә кайтасы килә. Тормыштан канәгать. Менә дигән гаиләм бар, балалар уку йортларында түләүсез укый. Медицина алга киткән. Шулай булгач, шушы уңайлыклар өчен ник көрәшмәскә?» – ди Рәис әфәнде.

### Кибеттә кишер үсми

Буа Татар дәүләт драма театры җитәкчесе Раил Садриев: «Балаларны тәрбияләргә кирәкми, алар – замана баласы», – ди. Аның әйтүенчә, 40 яшькә кадәрге буын чупа-чупс, кока-колалы тормышта үсте. Читтән кергән әйберләргә таянып, без бер-бер ярым буынны югалттык.

– Россия турында шундый әйтем бар. Утыз ел эчендә илдә теләсә нәрсә булырга мөмкин, тик 300 ел эчендә берни үзгәрми. Тарих кабатланып тора. Без Бөек Ватан сугышына эләкмәдек. Фронттан кайтучыларны тыңлап үстек. Ачлыкны үз башыннан кичергән әби-бабайлар сөйләгәннәрдән ипи кадерен белергә өйрәндек. Яшьләр эшкә яраксызга әйләнеп бара. «Пятерочка», «Магнит»та кишер дә, суган, бәрәңге дә үсми. Алар барысы да – китерелгән ризыклар. Адәм баласы эшләп ашарга тиеш. Битараф тормыштан айнытып җибәрү өчен шундый вазгыять кирәк, – ди Раил Садриев. – Ковид ул мунча алды булмәсе иде. Хәзер мунчасына кереп барабыз, тик әле парландырыгычына кермәгән. Ул – алда әле. Без көтә торган әйбер – депрессия. 40 яшьлек буын белән бәйләнгән ул. Алар башкача яши белми, чөнки барлыкта үскән. Тик кеше бер вакыт юклыкны да күрергә тиеш. Шуны күрә башладык, бу – чыныгу өчен сабакларның берсе. Хәзер кеше, авылларга кайтып, күбрәк үзенекен ашый башлаячак. Чупа-чупс суырып үскән малайлар, тормышка яраклаша алмыйча, депрессиягә күчеп, бу дөньядан китеп барачак. Алар кулыннан бер эш тә килми. Вазгыять ул – бүгенге көннең парадигмасы. Бөтен нәрсә – шушы факторлардан торган «уен кыры», яшәү рәвеше. Бу – көтелгән әйбер, шулай булырга тиеш. Әгәр килачәктә болай барса, кешелек дөньясы юкка чыгачак.

Соңгы вакытта Украинада барган махсус хәрби операциядә батырлык күрсәткәндә һәлак булган якташларыбызны җирләделәр. Алар – Ватан хакына дип гомерләрен кызганмаган яшь егетләр, ирләр. Бик авыр хәл, аналарның, хатыннарының, туганнарының бәгырьләре телгәләнә. Бу фаҗигаләрне авыр кичердек, берәү дә битараф калмады. Кызганыч, илебез үзенең газиз улларын югалтты. Яшьләр интернет геройларын түгел, үз каһарманнарыбызны белсен, аларның батырлыкларын онытмасын иде.

Сәрия МИФТАХОВА

**Фикер**

**Вәгыйз САНАТУЛЛИН, Лениногорск районы мәгариф идарәсе башлыгы:**
– Советлар Союзы таркалгач, күп нәрсә акчага кайтып калды. Кемнең яхшы айфоны бар, кемнең әти-әнисе яхшы эштә эшли, шуңа игътибар итәләр. Дәреслек аша балалар батырлыкны бары мәгълүмат итеп кенә кабул итә. Авырлыкны күрмәгән, нәрсә икәнен белмиләр. Безне әбиләр тәрбияләсә, яшьләрне интернет өйрәтә. Шуңа күрә фикерләүне без түгел, интернет формалаштырды. Бөтен бала да андый дип әйтәсе килми. Чикләүләр файдага булачак. Кола эчмичә, бургер ашамыйча да яшәп була. Коладан башка яшәдек, үз лимонадыбызны эчтек. Безнең илдә бөтен нәрсә дә бар, шуны кулланырга кирәк. Аларны эшләмәскә өйрәтәбез. Мәктәптә кизү тору өчен әти-әнидән күпме кәгазь җыярга кирәк. Мәктәп бакчасында да, бәрәңгедә дә эшләдек, беребезгә дә зыян килмәде. Яшьләрнең кумирлары – ярты башы кызыл, яртысы акка буялган, колагына алка таккан «тиктокер»лар. Алар – миллионер, бәрәңге казымыйлар. Кумирлар башка булырга тиеш. Әйдә, хезмәт ияләрен күрсәтик! Традицияләргә дә игътибар итми башладык. Мәктәпләрдә патриотик тәрбия эше бара, әмма без арттарак калабыз, башка юлларын эзләргә кирәк.

# КРЕДИТ КАНИКУЛЫ

## АННАН НИЧЕК ФАЙДАЛАНЫРГА?

**Хәзер инде кредитка да өмет юк! Россия Үзәк банкы төп ставканы 20 процентка кадәр арттыргач, күпләр әнә шулай дип көрсенде. Бу аңлашыла да. Шушы яңалыкка бәйле рәвештә банклар барлык төр кредит ставкаларын ике тапкыр арттырып куйды. Шул рәвешле бик күп проблемаларны чишәргә ярдәм иткән кредит рәсмиләштерү дә хәзер күпләрнең көченнән килми. Ай саен кредит түләп яшәүчеләрнең исә – үз кайгысы. Алга таба бурычымны вакытында түләп бара алырмынмы, моңа кадәр рәсмиләштергән кредитларның да ставкасын арттырып куймаслармы, дип борчыла алар.**

### Тота-каба ябышма

Дөрес, бу көннәрдә күпләрнең күңелен юатырлык яңалык ишетелде әле үзе. Россия Президенты Владимир Путин кредит каникулы турында яңа закон имзалады. Ул килеп туган вазгыять аркасында матди авырлык кичергән кешеләрнең кредит буенча айлык түләвен 6 айга кадәр кичектереп тору яки аның күләмен киметүне күздә тота. Бу быел 1 мартка кадәр рәсмиләштерелгән барлык төр кредитларга кагыла. Аннан пандемия чорында кредит каникулы алган кешеләр дә файдалана ала.

Бу хәбәрне ишетүгә, күпләр җиңел сулап куйгандыр. Әмма юрист Илнур Гарифуллин фикеренчә, кредит каникулы алам дип, банкка бүген үк чыгып йөгерергә кирәкми. «Закон әле бу көннәрдә генә үз көченә керде. Банклар өчен дә зур яңалык булды ул. Аларның болай да эше күп иде инде. Бер белгеч көненә уртача 15ләп килешү эшкәртте. Кредит каникулы да кертелгәч, эшләре бермә-бер артты. Шуңа күрә алар сезнең гаризаны бу көннәрдә генә эшкәртеп өлгермәскә дә мөмкин. Өстәвенә кредит каникулы алыр алдыннан соңгы бер айда керемнәрегезнең шактый кимүен раслау өчен дә бераз вакыт үтү кирәк. Бу урында шуны да искәртәсем килә: пандемия чорында кредит каникулыннан файдалану өчен, айлык керемнәрен киметеп, ялган белешмә ясатучылар да булды. Мондый акылсыз адымга барудан бер файда да юк. Банклар бу белешмәне барыбер тикшерәчәк. Андагы саннарның дөреслеккә туры килмәвен ачыклагач, банк сезнең гаризаны караудан баш тартачак», – ди юрист.

«Кредит каникулы» дигән төшенчә безгә, дөрестән дә, яхшы таныш. Хәтерләсәгез, пандемия чорында матди авырлык кичергән кешеләргә дә кредит буенча айлык түләүләрен вакытлыча кичектереп торырга рөхсәт иткәннәр иде. Илнур Гарифуллин сүзләренә караганда, кредит каникулларының пандемия вакытындагысы да, соңгысы да – килеп туган вазгыять аркасында кертелгән ярдәм чаралары. Юрист әлеге кредит каникулын гадәти ипотека каникулы белән бутамаска куша. «Ипотека каникулы турында» 76 нчы федераль закон бездә күптән гамәлдә. Кирәк чакта аннан ипотека кредиты алган һәркем файдалана ала. «Шуңа күрә айлык түләүләрне кичектереп торырга җыенсагыз, бу мөмкинлекне запаста калдырып, яңа имзаланган закон нигезендә кертелгән кредит каникулыннан файдаланыгыз», – ди юрист.

Яңа кертелгән каникулның тагын бер үзенчәлеге бар. Аннан фәлән суммага кадәр кредит алган кешеләр генә файдалана ала (тулырак – «сорау – җавап»та. – **Д.Г.**). Монда чамадан тыш зур суммадагы кредитлар турында сүз бармый. Бу аңлашыла да. Кредит каникулы нәкъ менә халыкның матди авырлыклар кичергән, ярдәмгә мохтаҗ өлешенә ярдәм итү өчен кертелә дә бит инде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бер яхшының бер начары булган кебек, әлеге мөмкинлекнең дә тискәре яклары шактый. Шуңа күрә Илнур Гарифуллин, кредит каникулыннан файдаланганчы җиде кат үйлап, бер кат кисәргә киңәш итә.

– Каникул алган кешенең автомат рәвештә кредит тарихы бозыла. Бу исә киләчәктә яңа кредит алырга туры килсә, яки булган кредитны рефинансларга уйласаң, кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин дигән сүз. Кредит каникулыннан файдаланган кеше, ким дигәндә, ярты ел дәвамында яңа кредит рәсмиләштерә алмаячак. Ник дигәндә, бу яллар сезнең айлык түләүләрне вакытында түләп бара алуыгызны шик астына куя, – ди юрист. – Күргәнегезчә, кредит каникулы авыртуны баса торган дару кебек: аны сызлауга түзәр чама калмаса гына эчәргә кирәк. Шушы мизгелдә авыртуны басып торса да, киләчәктә барыбер берәр тискәре йогынтысы килеп чыгачак. Шуңа күрә кредит каникулыннан башка чара калмаганда гына файдаланырга кирәк. Дөнья хәлен белеп булмый дип кенә, тота-каба ябышырга кирәкми.

### Банкта сакланса хәерле

Үзәк банк төп ставканы 20 процентка кадәр арттыргач, күпләр гамәлдәге кредит ставкалары да артмасмы, дип борчылды. Яшен тизлегендә әнә шундый имеш-мимешләр таралган иде. Әллә ни озак баш ватарга туры килмәде үзе. Россия Президенты Владимир Путин моңа кадәр рәсмиләштерелгән кредит ставкаларын үзгәрешсез калдырырга кушты. Ләкин бу бары тик ипотека кредитларына гына кагыла. Калган төр кредит ставкалары турында әле дә булса анык кына җавап юк.

Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов фикеренчә, бу очракта борчылырга җирлек юк.

– Әгәр сезнең ипотека, куллану яки автокредитыгыз бар икән, сезнең кредитның процент ставкасы артмаячак. Аны ничек түләгән булсагыз, алга таба да шулай түләп барачаксыз. Яңа кредит рәсмиләштергән очракта гына аны шушы чамадан тыш зур ставкалар белән бирәчәкләр. Дөрес, дәүләт ярдәме белән тормышка ашырылган ташламалы ипотека программасы әле дә гамәлдә. Аңа эләгә алсаң, бик яхшы. Юк икән, кредитны 15–20 процент белән алырга туры киләчәк. Мондый ставка белән кредит рәсмиләштерү отышлы түгел, билгеле, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Ил башлыгының рәсми боерыгыннан соң, «Саклык банкы», «ВТБ», «Альфа-банк» кебек эре банклар клиентларын беренчеләрдән булып тынычландырырга ашыкты – гамәлдәге кредит ставкалары артмаячак. Бүген әлеге банкларда ипотеканы 15–20 процент белән рәсмиләштерергә мөмкин. Кертемчеләргә исә акчаларын 23 процентка кадәр ставка белән сакларга тәкъдим итәләр.

– Соңгы 22 елда икътисадтагы дүртенче кризис инде бу. Соңгы тапкыр мондый югары ставкалар 2014 елда күзәтелгән иде. Ул чакта төп ставка 17 процентка кадәр күтәрелде. Аннары 1,5 ел эчендә ул акрынлап төшеп бетте. Төп ставка югары булганда икътисадның үсә алмавы көн кебек ачык. Шуңа күрә бу – вакытлы күренеш, – ди Фәнис Хөсәенов. – Безнең халыкның 80 процентының банкта кертемнәре юк. Булган очракта да алар өчен куркырга кирәкми. Алар банкларда тулысынча саклана. Сез аны теләсә кайсы вакытта ала аласыз. Әмма бу акчаны кая куярга? Аңа 10 телевизор яки 100 килограмм карабодай сатып алудан ни мәгънә? Шуңа күрә ашыгып карарлар кабул итмәгез. Сабыр булыгыз.

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов та бүгенге шартларда артык хискә бирелмәү яклы. Якын арада ипотека рәсмиләштерергә җыенган кешеләргә бераз көтәргә киңәш итә. Ник дигәндә, төп ставка арту белән барлык төр кредит ставкалары гына түгел, торак бәясе дә котырып үсәчәк. Кертемчеләрдән дә аек акыл сорала.

– Депозит ставкаларын кертем срогы беткәч кенә яңадан карарга була. Килешүне вакытыннан алда өзгән очракта кертем ставкасы 0,1 процент кына булырга мөмкин. Шуңа күрә кертемнең срогы тулганчы көтәргә, аннары инде банклар тәкъдим иткән депозит ставкасы белән яңадан килешү төзергә кирәк, – ди Илгизәр Гайнетдинов. – Бүгенге вазгыятьтә акчаны банкта саклауны дәвам иттерергә кирәк. Ник дигәндә, акча алсаң да югала. Аны хәзер доллар, еврога алыштырудан мәгънә юк. Банктагы кертемнәрнең 1,4 миллион сумга кадәр өлеше иминиятләштерелгән. Банклар банкротлыкка чыккан очракта да кешегә кертемнәренең әнә шулкадәр өлеше тулысынча түләнәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

**Сорау – җавап**

▸ **Кемнәргә бирелә?**
✓ Гади халык, кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы вәкилләренә.

▸ **Нинди кредитларга кагыла?**
✓ 2022 елның 1 мартына кадәр рәсмиләштерелгән барлык төр (ипотека, куллану, автокредит) кредитларга.

▸ **Пандемия чорында кредит каникулыннан файдаланган булсаң нишләргә?**
✓ Яңа кредит каникулыннан андый кешеләр дә файдалана ала.

▸ **Күпме вакытка алып була?**
✓ 6 айга бирелә. Аны иртәрәк тә тәмамларга була. Моның өчен банкка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

▸ **Нидән гыйбарәт?**
✓ Кредит буенча айлык түләүне вакытлыча туктатып тору яки берничә айга аның күләмен киметү. Моны банк түгел, кредит түләүче кеше үзе сайларга тиеш. Уйламаганда мөмкинлекләр килеп чыкса, каникул вакытында да кредитны тулысынча ябарга яки аның бер өлешен капларга мөмкин.

▸ **Аны алу өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш?**
✓ Кредит каникулы бирүне сорап мөрәҗәгать иткән көнгә бер ай кала кешенең айлык керемнәре, ким дигәндә, 30 процентка кимегән булырга;
✓ кредит күләме билгеләнгән максималь чиктән артмаска;
✓ кеше исемендә түләнеп бетмәгән башка кредитлар булмаска тиеш.

▸ **Нинди максималь чик билгеләнгән?**
✓ Ипотека кредиты – 2 миллион сум;
✓ автокредит – 600 мең сум;
✓ шәхси эшмәкәрләр өчен куллану кредиты – 300 мең сум;
✓ физик затлар өчен куллану кредиты – 100 мең сум;
✓ физик затларның кредит карталары буенча – 100 мең сум.

▸ **Кайчан мөрәҗәгать итәргә?**
✓ 2022 елның 1 мартыннан 30 сентябренә кадәр, үзең кредит алган оешмага.

▸ **Нинди документлар кирәк?**
✓ 2021–2022 ел өчен 2-НДФЛ белешмәсе;
✓ Мәшгульлек үзәгеннән эшсез дип тану турында белешмә;
✓ «больничный» кәгазе (1 айдан күбрәк срокка);
✓ айлык керемнәр кимүне раслаган башка документ.

▸ **Минуслары бармы?**
✓ Кредит каникулы вакытында айлык түләү туктатылып торса да, банклар кредит өчен процентлар исәплүне дәвам иттерәчәк. Аларны каникул тәмамлангач түләргә туры киләчәк. Димәк, кредит буенча артык түләнгән сумма (переплата) да артачак дигән сүз. Кредит каникулы гамәлдә булган айлар хисабына кредитның түләү вакыты да озаячак.

## ӨЧ БАЛА БЕЛӘН ТОЛ КАЛГАН ИР:

# «СИЗЕНСӘМ ДӘ, ӨМЕТЛӘНДЕМ»

**Чирмешәндә яшәүче Рифат Мөхәммәтшин өч кызы белән тол кала. Хатыны Галияне югалтканына бер ай да юк әле.**

Алар үрнәк гаилә булып яши. Йорт-җирнең төзеклеге, бакчаларның матурлыгы, өйдәге чисталык буенча аларга тиңнәр булмый. Кунакка килгән кешеләр дә йортта бер генә артык әйбер булмауга, пөхтәлеккә сокланып китә. Боларның барысы да Галиянең тырыш хезмәте нәтиҗәсе була. Ашка-суга уңган, нәрсәгә тотынса, шуны башкара торган ханым була ул. Тик матур тормышларына күз тия. Балаларга әнинең иң кирәк вакытында ул китеп бара. Галиягә бары тик 39 яшь була.

Мөхәммәтшиннар өч кыз үстерә. Олысы – 7 нче сыйныфта, икенчесе 1 нчедә укый, кечкенәләренә 3 яшь тулган. Галия «Каенкай» балалар бакчасында тәрбияче булып эшләгән.

– Өченче балабыз белән декреттан чыккач, бер ай эшләп калды. Ковид белән авырый башлады. Бер ай хастаханәдә ятты. Инде савыгып бетте дигәндә, тагын авырый башлады. Бу юлы ашказаны тирәсе авыртудан зарланды. Тикшерелә торгач, ковидның ашказаны асты бизенә зыян салуын, чирнең катлауlануын әйттеләр, – ди Рифат.

Галиягә беренче операцияне Чирмешәндә ясыйлар. Бар да уңышлы килеп чыга. Әмма чир чигенми. Аны Казанга күчерергә карар кылына. Бередә тагын ике тапкыр операция ясала. Галия бер дә начар уйлар белән яшәми. Авыруны җиңәм, балаларым янына өйгә кайтам, ди ул. Сабыйлар әниләре белән телефоннан видеоэлемтә аша сөйләшеп тора. Хәле дә яхшырган төсле була. Әмма Галия тагын авырып китә. Шул көнне Рифат Казанга килә. Төнлә Галияне реанимациягә күчерәләр. Тагын бер операция кирәген әйтәләр. Әмма табиб Рифатка алып калып булмасын сиздерә. Кан анализларының да яхшы түгеллеген әйтәләр. Ашказаны асты бизе бөтенләй эштән чыккан була.

– Үзем дә сизендем. Әмма яхшыга өметләндем. Яшәр дигән идем. Тик язмыштан узмыш юк. Диндә булгач, кайчан да булса, фани дөньядан китәсен аңлап яшисең. Балаларым да көчле булырга тырышты. Кечкенәсе әле дә әнисе каядыр киткән дип уйлый. Олыраклары аңлады инде, – ди Рифат.

Әниләре үлгәч, сабыйларга ярдәм итүчеләр күп булган. Рифат баштарак бу хәлгә уңайсызланган да. Әмма якыннары, сәдака бирүчеләр, балаларыңа дип бирәбез, дигәч, каршы килмәгән. Ул безнең дә газета аша ярдәм оештыруыбызга каршы килде.

– Кеше кайгысын үзенеке итүче кешеләр шулкадәр күп икән. Галияне озатырга да йөзләгән кеше килде. Бер белмәгән кешеләр булышты. Галия авырганда да күпме кеше хәлен сорап торды, ярдәм күрсәтте. Безнең гаиләне авыр вакытта ташламаган һәр кешегә чиксез рәхмәтемне җиткерәм, – ди Рифат.

Гөлгенә ШИҺАПОВА


Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

## БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

**Оештыручылар – «Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте**

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:
**I урын – 10 мең сум;**
**II урын – 7 мең сум;**
**III урын – 5 әр мең сум күләмендә ике премия.**
**Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.**

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе.

**БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:**
«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин. Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы – 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222 09 70, 8917 927 00 40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән бергә җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе. Реклама, 16+


# *Карга оя кормыйча, яз җитми*

**«ВТ»ның даими синоптигы, Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче Әмир Шәрәфиев бүгенге салкыннарны фаразлаган иде. Кач ману вакытында булмаган салкыннар мартта күзәтелергә мөмкин, дигән иде ул. Юраганы юш килде. Яз кояшы матур итеп карый башлагач кына кышкы киемнәрне яңадан алып кияргә туры килде.**

– Февральнең икенче яртысын күзәтеп бардым. Ул нормадан 6, 7 градуска җылырак булды. Шуңа да март ае салкын булыр дигән идем. Әле бу суыклар озакка барачак. 25ләренә кадәр салкын һава торышы көтелә, – ди халык синоптигы. – Салкыннар булса да, яз кояшы әкренләп елмая, җиле дә бар. Шулай әкрен генә кар да кимеп бара. Чын язны апрель башында көтегез. Сыерчыклар кайтуга, яз килә. Әле җылы булмагач, 19 февральдә кайткан кара каргалар оя кора алмыйча йөри. Димәк, җылы көннәргә ерак әле.

КФУ галиме, орнитолог Илгизәр Рәхимов та каргаларны күзәтә икән. Каргаларның кайберләре китеп тә тормый, ди.

– Иң көчлеләре, яшәренә ышанганнары китми. Каргалар гына түгел, меңләгән үрдәк, миләш чыпчыклары да җылы якларга китми хәзер. Казан паркларында кошларга ашарга ризык җитәрлек. Энергиясен әрәм итеп китеп тормый алар. Китсәләр дә, әллә кая ерак очмыйлар. Күбрәк Урта диңгез буйларына, Кавказ тирәләренә барып урнашалар, – ди Илгизәр Рәхимов. – Кошларның тән температурасы – 40 градус. Алар туңмый. Туңсак, без тун киябез, аларның каурыйлары бар. Очып та җылыналар. Безгә каргалар килүен килделәр, әмма ашарга булмагач, оя кормыйлар әле. Чүплекләрдән азык эзлиләр. Көннәр җылытып, кар эрегәч, аларга ризык артачак. Салкыннарны алар да сизә. Хәтта ояларын да төзәтмичә торалар. Аларга да җылы кирәк. Алар оя коруга, яз җитәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

## НӘФИСӘ САБИРҖАНОВА:

# «БӘХЕТСЕЗ БУЛУ – ӘДӘПСЕЗЛЕК»

**«Нәфисә Сабирҗанованың көче нәрсәдә?» дигән сорауга аның укучысы, тамашачысы, ихласлыкта, дип җавап бирер иде. Җырлары шуңа популяр, шигырьләре шуңа күңелдә озак сакланадыр, мөгаен. Күптән түгел без аны яңа яктан ачтык. Хәер, безме, улмы икән? Популяр шагыйрә, җырлар авторы, журналист куркыныч авыру турында ачылып сөйләшүгә ризалашты. Нәфисә САБИРҖАНОВАның тормышында, иҗатында нинди үзгәрешләр булган – без шул хакта сөйләштек.**

**:: Сез нәфис хатын-кыз үрнәге булып, социаль челтәрләрдән елмая, матур җырлар белән сөендерә, лирик шигырьләрегез белән уйландыра идегез. Берара юкка чыктыгыз, аккаунтларыгыз ябылды һәм күптән түгел генә бөтенләй яңа кеше булып ачылдыгыз. Нәфисә апа, нәрсә булды, ниләр кичердегез, укучыларыгыз белән ачылып сөйләшергә кайдан көч таптыгыз?**

– Социаль челтәрләргә, халык белән аралашуга гамь калмый торган вакытлар була. Мин әнә шуны кичердем. Аның башы да гыйбрәтле, әйтерсең лә мине уятып җибәрделәр һәм тормышка чытырдап ябышып көрәшергә мәҗбүр иттеләр. Узган елның сентябрь ахыры иде ул, Казанга дусларыбызның никах туена бардык. Мәчеттән чыккач, миндә кинәт кенә хатын-кыз авырулары кузгалып китте, эчем кисеп-кисеп авырта башлады. Әлмәткә шактый вакыт кайтасы булганга, даруханәгә тукталып, дару алдык, шуны юлда да, кайткач та эчтем. Икенче көнне табибка бару турында уйламыйм да, үзлегемнән дәваланам, өч көндә терелгән кебек тә булдым. Дүртенче көндә теге даруның «файдасы» тиде – сул як күкрәктә түзеп булмаслык авырту башланды. Шул чакта күкрәктә ниндидер каты шеш барлыгын тойдым. Табиб исә, беренче карауда ук, яман шеш, стадиясе дә зур, дигән диагноз куйды. Аңа ышанырга теләмичә, эчтән генә сүгеп, Әлмәт телевидениесендәге «Җомга» авторлык тапшыруымның юбилеена әзерләнә башладым. Янәсе, миннән башка кем үткәрсен инде аны?! Шулай итеп вакыт үтте. Туган көнемә балалар кайткач, аларга хәбәр иттем. Тынсыз, өнсез калдылар. Шуннан соң улым: «Әни, әйдә җыен, Казанга китәбез», – диде. Анда баргач, диагноз тагын бер кат расланды.

> Хәзер шул хәлләрне уйлыйм да, мөгаен, мин Ходай Тәгаләнең иң яраткан бәндәседер, дим. Ул мине гомер өчен көрәшергә мәҗбүр итте. Әгәр мәчеттә үк «хәбәр» биреп уятмаган, үзлегемнән дару эчеп чиремне көчәйтмәгән булса, мин әле һаман берни белми йөрер идем. Упкын читендә басып торганмын бит.

Башта үземдә паника булды, куркып калдым. Тора-бара бүтән вариант булмавын аңладым. Хәлемне ничек бар, шулай кабул итәргә, сабыр булырга тырыштым. Минем истерикага бирелүемнән кемгә файда? Балаларымамы, иремә, якыннарымамы, үземәме? Мин кичерәсен башка кеше кичермәс дигән хакыйкатьне аңлагач, ниһаять, сулыш алу иркенәйде.

Социаль челтәрләргә үзем кичергәннәрне язуымның сәбәбе берничә. Мин аны озак уйладым. Чир тышкы кыяфәтне, киенү, гомумән, яшәү рәвешен үзгәртте. Бу, әлбәттә, тирә-юньдәгеләрдә күп сораулар тудырды. Тапшыру алып баргач, экранда да күренергә кирәк. Мин исә баштагы мәлләрдә стендапсыз эшләдем. Нигә алай, нигә болай дигән сораулар күбәеп киткәч, уптым илаһи җавап бирергә теләп, үзем турында пост яздым. Ахыр чиктә, бөтен кеше алдында ихлас буласым килде. Шулай да төп сәбәп, минем хәлгә калган кешеләр бихисап бит, дигән уй иде. Без дә яшәргә лаеклы, без дә – шундый ук кешеләр, безне кызганырга кирәкми, дип әйтәсем килде. Бәлки киңәшләребез белән уртаклашырбыз, бергәләп көрәшербез дигән өмет тә бар. Үземә дә бу зәхмәтне җиңгән үрнәкләр бик кирәк.

**:: Мөгаен, бу сезгә иң еш бирелә торган сораудыр: тормышның тәмен югалтмас өчен нишләргә (нинди булырга) кирәк?**

– Эх, әгәр без һәрбер вак-төяккә борчылган кебек һәрбер вак-төяккә шатлана да белсәк икән! Без күпкә бәхетлерәк яшәр идек. Җыен юк-барга хафаланырга кирәкми, дияр идем. Тормышның кадерен белик. Ул – безнең иң зур байлыгыбыз. Табиб миңа күбрәк җәяү йөрергә кушты. Хәзер җәяү барганда каршыга килгән кешеләрне күзәтәм. Елмайган йөз күренми! Барысының йөзләре җитди яки чытылган, башлар аска иелгән, бигрәк курыныч. Бөтен бәла, хәтта чирләрнең башы да шатлана белмәүдән бит.

Соңгы вакытта мин «Рак каян килеп чыга?» дигән темага фәнни язмалар күп укыйм. Аның беренче сәбәбе – нәселдәнлек. Безнең нәселдә бу чирнең булганы юк. Калган сәбәпләргә килгәндә... Холкым буенча мин – позитив кеше, зарланырлык җирдә дә зарланмыйм, юктан да рәхәт табып, күңелне күтәрәм, яратып-яратылып яшим. Минем очракта төп сәбәп – стресс. 22 яшьлек, өйләнергә йөргән олы улыбыз Айдарны югалту кайгысы ул бетә яки кими торган түгел, ул – гомерлек.

Сазлыкка баткан кеше нишли? Баскан урында әле бер, әле икенче аягыны алып, таптанып торудан файда юк. Аннан чыгар өчен кул белән таянып, этелеп китәргә нинди дә булса каты, ышанычлы урын эзлисең. Тапкан очракта да, ул әле баладән тулаем котылу түгел, ә бәлки беренче адым гына. Минем таяныр урыным – гаиләм, якыннарым, дусларым, аларның җылы сүзләре, догалары булды. Тик кешеләрдән ярдәм көтеп утыру гына коткармый, үзеңә дә тырышу кирәк. Мәсәлән, игелек кылу, үзеңнән дә авыррак хәлдә калган кешеләргә рәхмәт өмет итмичә ярдәм итү беренче чиратта синең үзеңне коткара. Каядыр бару, күңел ачудан да вакытлыча онытылып торырга була. Әмма аннан соң кире чынбарлыкка кайту тагын да авыррак булырга мөмкин. Ә игелекле эштән соң, вакытым заяга узмады лабаса, дигән уй бик тә ярдәм итә.

**:: Сез – шоу-бизнеста да, шигърияттә дә үз урыныгызны тапкан кеше. Авыр чакта ярдәм кулы сузучылар булдымы?**

– Социаль челтәргә язгач, җылы сүз, яхшы киңәш бирүчеләр бик күп булды. Иҗатташ дусларым да, ярдәм кирәк булса, без янәшәңдә, дип яздылар. Әлегә минем өчен ярдәм бары тик – дога. Дәваланам, химия алам, операциягә әзерлиләр. Препарат үз эшен эшләп, яхшы нәтиҗә бирсен иде, дип телим. Үземне озын, бәхетле тормышка программалаштырам.

**:: Сез көчле хатынмы?**

– Ике комментарийның берсенә, син – көчле хатын, дип язалар. Бәлки. Тыштан мин күпләргә шулай күренәмдер. Хәсрәт кичергәч тә, елмаеп, экранда тапшыру алып барырга, сәхнәгә чыгарга туры килде. Хәзер дә кеше алдында кайгыга батып йөрмәскә тырышам. Беләсезме, мин бер мизгелдә бәхетсез булу ул – әдәпсезлек (неприлично) дип аңладым. Керләнгән кием, күлмәккә тамган тап кебек. Шуннан соң үз аңым, уйларым өстемдә эшли башлады. Иң кызыгы шул: күпмедер вакыт үткәннән соң, үземне бәхетле итеп сизә башлаганда, минем тормышымда берни дә үзгәрмәгән иде. Гаҗәп бит! Ә менә табиб, рак ул – нәкъ көчле хатыннар чире, диде. Бөтенесен әчкә җыюның нәтиҗәсе хәзер чыга, ахрысы. Шулай булгач, дөрес микән ул көчле хатын булу, белмим.

**:: Бер әңгәмәдә сез: «Шоу-бизнеста да, шигърияттә дә ихласлык югалды шикелле», – дигәнсез. Хәзер хәлләр ничегрәк?**

– Тормышның бөтен өлкәсендә дә ихласлык, эчкерсезлек югалып бара кебек. Элекке кыйммәтләр арткы планда калды. Ә ихласлык турында ул әңгәмәдә укучы булган чакларымны сагынып әйткәнмендер. Мәктәптәге балалар белән мөнәсәбәтләр, аларның самими күз карашлары, ни уйлый – шуны әйтүләре җитмәгәндер ул вакытта минем тормышта. Постлар яза башлавым да ихлас сөйләшүгә чакыру инде ул.

**:: Гаилә турында сорамасак, дөрес булмас. Тыл көчле булмаса, сынауларны узып булмый торгандыр.**

– Ул яктан мин бәхетле, тылым нык. Равил, мөгаен, мин терелеп бетүгә, кулинария буенча китап язар, ахрысы *(көлә)*. Туклануның үз җае бар хәзер, шуңа күрә ирем кибеткә үзе йөри, минем бөтен рационны белә. Кирәк икән укол сала, кирәк икән чәчемне кырка *(көлә)*. Улым Наил белән кызым Альбинаның да ярдәмнәре зур, Аллаһка шөкер. Ә оныгым Тамерлан – гомумән, минем антидепрессант! Исән-сау гына булсыннар.

**:: Шигърияттә кумирыгыз бармы?**

– Күңелем белән берәр сорауга җавап эзләгәндә, нәрсә эшләргә белми аптыраганда, мин Саҗидә Сөләйманова китабын ачам. Аның иҗаты искиткеч бит ул. Беренче укыганда юллар арасындагы яшерен мәгънәгә бәлки төшенеп тә җитмисеңдер, алар укыган саен ачыла, яңа төсмерләргә байый. Ә инде тормыш укытучым дип мин Клара Булатованы атыйм. Аның гамәлләре, үз-үзен тотышы, дөньяга мөнәсәбәте – үзе бер мәктәп. Мине шигърияткә, журналистикага кереп китәргә мәҗбүр иткән кеше дә – Клара апа Булатова.

**:: Күңелегезгә бик якын булган өч җырыгызны атагыз әле.**

– Әлмәттә яшәүче композитор Рәис Нәгыймов, шигырьләрең җырлап тора дип, берничә шигыремне сорап алды. Аның гөрләп иҗат иткән вакытлары иде ул. Мин исә, алар үзем өчен генә язылган, мин – математик, филолог түгел, дип карыштым да әле. Рәис абый сүзендә нык торды, нәтиҗәдә берничә шигыремне алып, аның дүртесенә тиз арада көй язды. Шуларның берсе – Лилия Муллагалиева башкаруындагы «Күрми китмә» дигән җыр. Беренче җырым һәм өч авторы да Актаныштан булуы белән кадерле ул миңа. Икенчесе – хәзер халык җырына әйләнеп баручы «Ромашкалар» җыры. Аны инде русча да, төрекчә дә җырлыйлар. Гүзәл Уразованың кулы җиңел булды. Өченчесе – күңел халәтемә аеруча туры килә торган «Ак хыяллар» җыры. Аны Айдар Галимов башкара. Бу җырларның гомере озын булды, шөкер.

**:: Бик катлаулы чорда яшибез. Ничек уйлыйсыз, тормыш элеккеге эзенә кайтырмы? Кешеләр элеккечә яши алырлармы?**

– Элеккеге законнар да, элеккеге тормыш та башка юк һәм булмаячак та дип уйлыйм. Кешеләр дә үзгәрде. Барыбыз да диярлек глобаль проблемалар турында сөйли башладык, бөтенебез дә сәясәтче булып китте, акыл өйрәтергә һәвәсләндек. Хәтта сәяси килешмәүчәнлек аркасында дусларын югалтучылар да бар. Безгә бу кирәкме? Сүз дә юк, югалып калдык, ышаныч бетте. Миңа калса, һәрберебез үз даирәбездәге вак кына нәрсәләрне хәл итсәк, элеккеге хаталарыбызны төзәтү өстендә эшләсәк, күбрәк игелек кылырга омтылсак, дөнья күпкә яктырыр, яхшырыр кебек миңа.

**:: Балачактагы иң матур бер мизгелне искә төшерик әле. Аның тәме, төсе, исе нинди?**

– Алма тәме, яшел төс, чәчәк исе… Соңгы араларда мин үземнең кайчандыр бик бәхетле булган мизгелләремне искә төшерә башладым. Шуларның берсе – әткәй-әнкәй яшәгән ихатадагы әткәй утырткан алма бакчасында корып куелган, әнкәй марлядан теккән чыбылдык. Мин аны нык ярата идем! Рәхәт иде җәйге кызу төннәрдә, юка җәймә ябынып, аның эчендә йоклау. Ә кайвакыт йоклый алмый ятарга… Әнкәй чыбылдыкның бер ягында форточка кебек ачык урын калдырып теккән. Мин шуның аша күренгән йолдызлы күккә карап ятам. Балачакның самими хыялларына чумып: ничек мин үсеп җитәм, нинди чибәр, белемле һәм танылган кеше булам, нинди матур гаилә корам, балалар үстерәм, ничек матур итеп үз йортымны бизим…

> Ә бит бәләкәй кызның бөтен хыяллары тормышка ашкан, тик минем генә хәзер шул чыбылдык эченә кире кайтасым килә. Бала чактагы кебек, булмастай эш юклыгына һәм әле барысы да алда икәненә нык ышанасым килә.

Гадәттә, авылларда яшелчә һәм бәрәңге бакчасы гына булса, Актаныш ягында исә шуларга кушып тагын өченче бакча да бар. Ул – өй кырындагы алма бакчасы. Безнең дә шулай иде. Минем әткәй – 1917, әнкәй 1922 елгы. Без гаиләдә 4 бала: өч кыз, бер малай үстек, мин – төпчеге. Алма бакчабызда һәрберебезнең үз алмагачы бар. Аларның һәркайсы үзенә генә хас тәмле алмалар бирә. Хәтта ул алмаларның тәме, формасы агач «хуҗасы»ның холкына да туры килгән кебек иде миңа. Эх, әнкәйле-әткәйле, самими хыяллы чаклар сагындыра шул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

## ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

# СОВЕТ МУЛЛАСЫ

### ХИКӘЯ

< Дәвамы. Башы 25 февраль, 4 март саннарында

Хәер, тормышларында берни дә үзгәрмәде. Гарәпшаны болай да бер генә аштан да калдырмыйлар иде, хәзер шуларның түрендә утырып, йоласына китереп алып бару гына аның бурычына әйләнде. Масаймады, гадәт-тотышлары үзгәрмәде. Бу яшьтә үзгәрерлек тә түгел инде ул. Таягына таянып, урам буйлап каядыр теркелдәүче хәзрәт авылның бер күркенә әверелде. Мулланы кемгәдер чакырганнар, димәк, дин дә яши, ашлар үткәрелә, кул күтәреп догалар укыла, шифалы Коръән тозы табын әйләнә, димәк, тормыш та дәвам итә. Замана болытлары күкне каплап алса да, иман нуры барыбер балкый, җиһанны яктыртырга юл таба…

Вакыт кына Гарәпшадан сәламәтлеген суыра торды. Сыңар күзе дә начарайды. Ул инде элеккечә җәһәт кенә авылның теләсә кайсы йортына да барып җитә алмый, андый-мондый мәҗлес оештыра калсалар, хәзрәтне машина белән килеп алырга туры килә. Болай кешегә мәшәкать ясап йөрү Гарәпшаның күңеленә бер дә ятмады. Һәм ул моннан ике ел чамасы элек муллалык вазыйфасыннан китүе хакында җәмәгатькә гает намазыннан соң үзе хәбәр итте. Дөньялар да үзгәрде бит, күрше авылларда әнә мәчетләр төзеп чыгарга керештеләр. Аларга да гыйбадәт йорты бик кирәк. Шушы эшне башкарып чыгарлык, халык арасында абруе булган, мәхәлләне кулда тотарлык алмашчысын Гарәпша үзе сайлады. Соңгы вакытта дин мәсьәләсен тирәнтен өйрәнүгә керешкән, пенсиядә булуына карамастан, көче-егәрлеге ташып торган Фарухны тәкъдим итте ул. Шөкер, ялгышмады. Әнә мәчетнең дә манарасы калкып тора, биш вакыт намазга өндәп азаны да бөтен тирә-юньгә яңгырый. Ул төзелеш эшләрен Гарәпша, әлбәттә, ерып чыгарлык хәлдә түгел шул. Ни кызганыч, динне дәүләт яңадан санлый башлагач кына, аяк-кулларының хәле китте, гәрчә зиһене һаман да элеккечә ачык калса да…

– Исәнме, Гарәпша абый! – дигән тавышка ул сискәнеп борылды. Аннан шул якка ике кулын сузды. Теге кеше аның белән исәнләште.

– Исән генә, кем әле, исемең баштан чыккан…

– Дамир бу, Гарәпша абый!

– Ә, шулай шул, Дамир дип тора идем үзем дә. Әйдә, утыр, дөнья хәлләрен сөйлә бераз. Персидәтел эше авырдыр инде бу заманда?

Дамирның тирән итеп көрсенүе бу сорауга бик аермачык җавап иде. Борыны белән Гарәпша тегенең авызыннан атылып чыккан хәмер исен дә тойды. Кичәгедән калган түгел, бүген салган хуҗалык рәисе, иртә баштан…

– Үзем генә беләм инде аның ни икәнлеген, Гарәпша абый!

– Алай икән…

– Хезмәт хакын түләргә акча юк, халык зарлана. Әйтерсең, мин колхоз кассасын үз кесәмә салып куйган! Бөтен иле белән шул хәл, булмаганны кайдан җиткерим?!

– Соң, бөтен иле белән икән, ник башыңны катырасың? Намусың чиста, димәк, хафаланасың юк.

– Аңлатып буламы соң аны кешеләргә?! Бераз гына каралты-кураны яңартып, ызбаны тышлаган идем – китте сүз, китте гайбәт!

– Гайбәт язык ул. Ә инде үз ихатасын да сипләп тора алмаган җитәкче ничек итеп калхуз кадәр калхузны алга җибәрсен?! Үзеңнекен карап, дөрес эшләгәнсең, энем.

– Җылы сүзеңә рәхмәт инде, Гарәпша абый! Әнә мәчет тә күтәреп куйдык, анда күпме көч керде. Аны белүче дә юк.

– Мәчет өчен рәхмәт үзеңә.

– Бер мин генә түгел инде…

– Бу җирдә син хуҗа бит, синең фатыйхаң бирелмәсә, авылыбызда азан мәңге яңгырамас иде… Менә син шулай хафага төшәсең, халык, калхуз өчен борчыласың. Бөтен иленең астын өскә китергән Горбач белән Елсун бөтенләй төн йокламыйдыр инде… – Гарәпша әллә Ельцин фамилиясен җиңә алмады, әллә инде махсус үртәп, илнең хәзерге башлыгын Елсун дип кенә йөртә иде. – Кызык инде бу дөнья дигәнең. Ризыгы бар, дене юк иде. Хәзер менә мәчет-чиркәүләрне яңадан торгызалар, муллаларга указ өләшәләр, ләкин халык һаман да разый түгел. Һаман ни дә булса җитми…

– Шулай шул, Гарәпша абый. Кеше бит барысына да өстән-өстән генә, үз җаен уйлап кына карарга өйрәнгән. Төбендә ни яшеренгәнен беләсе дә килми, ник аның белән үз башын бутап ятсын ди ул?!

– Анысы хак, энем… Син дә башыңны авырттырма, җиңелрәк кара ул нәрсәләргә. Син генә үзгәртә алмаган әйберләр бар бит әле бу дөньяда.

– Авыл халкы теленә колхозны бетергән персидәтел булып керәсе каласы килми бит, Гарәпша абый…

– Аның каравы мәчет салдырган кеше. Анысы да тарихка языла. Аннан соң, тарих нәрсә ул?! Һәр вакыйга гамәл китабыңа теркәлә бит. Тегендә баргач, яхшылык-яманлыкларны шул китапка карап, бизмәнгә салып үлчәрләр.

– Шулай дисеңме?!

– Шулай дими тагын… Белеп әйтәм, чүтеки, азмы-күпме мулла булып торган кеше бит мин.

Персидәтел Дамир торып басты, киерелеп куйды төсле.

– Синең белән сөйләшүе рәхәт, Гарәпша абый! Тынычландыра беләсең. Икенче берәве синең урында тетмәмне тетәр иде. Иртәдән салып карт кеше янына килгәнсең, тәмуг кисәве дип әйтергә дә күп сорамыйлар. Ә син менә әллә нинди, икенче…

– Сине хөкем итеп утырырга хакым юк, энем. Икебезнең дә гамәлләренә бәяне бары тик Ходай каршына баскач кына белербез… Аннан соң, син үзеңнең ялгышларыңны танийсың бит, алардан ояласың, кеше сүзенә эчең поша. Ә бу – үзенә күрә иман күрсәткече инде.

Дамир белән саубуллашкач, Гарәпша карт кире өйгә керергә карар кылды. Урыныннан торыйм гына дигәндә, үзенә эндәшкән тагын бер тавыш туктатып калды. Үзләреннән ике йорт арасы гына яшәгән малай, Рәмис икән. Аны Гарәпша кайдан да таный. Бигрәк тә акыллы, итагатьле, кызыксынучан егет. Үзенең оныклары белән бер тирәдәрәк булса да, тегеләр Рәмис шикелле картның күңел түренә үтеп керерлек итеп сөйләшеп утырырга яратмый. Ә бу сораштыра, нәрсәдер теркими шунда. Фронтта булган елларны да, аннан соңгыларын да…

– Ә, Рәмис, синмени әле бу?! Кайдан җил ташлады?!

– Гарәпша абый, әни кушуы белән килдем.

– Йә, ни йомыш белән җибәрде, сөйләп кара.

– Иртәгә унга килеп, сеңлемә исем куштыра алмыймы? – ди.

– Һай Аллам, тагын? Мин күптән мулла түгел бит! Фарух абыеңа җибәргәндер, ялгышкансыңдыр!

– Юк, ялгышмадым. Фарух абыйны бүлнискә салганнар, болай зыянлы түгел, диләр, ләкин ике атналап ятасы икән. Булдырсаң, бу эшне син генә булдырасың инде, Гарәпша абый!

– Анысы шулай да бит… Әле кай арада әниең корсакка узып, бала табарга өлгерде?

– Сеңлемә биш яшь инде, Гарәпша абый, син аны беләсең. Аңа син үзең исем кушкан идең, тик ул авыррак исем булып чыккан, диләр. Шуңа күрә сеңлем бертоташ авырый, бүлнис юлыннан кайтып кергәне юк. Менә хәзер шуны төзәтәсе иде…

– Ә, аңладым алайса. Фарух мулла кайтканны гына көтмисезме соң?

– Юк шул, барысы да алдан әзерләнде бит. Фарух мулланы да чакырган идек, бүген иртән «ашыгыч ярдәм» белән алып киткәннәр үзен. Синең бу йоланы үтәүгә ул ризалыгын бирде, диде әни.

– Ә, Фарух беләмени… Унга килергә дисеңме?

– Унга. Мин сине үзем кереп алам.

– Яхшы, унга алайса. Сеңлеңә ни ат кушабыз?

– Лилия.

– Лилия. Матур исем икән тагын үзе. Ярый, унынчы яртыдан да калмый юлга чыгармын!

Гарәпша карт, ашыга-ашыга, өйгә атлады. Шәмсекамәр карчык сандык өстенә утырган көе радио тыңлый. Бүлмәгә моңлы җырлар агылган.

– Сүндер әле шуны, – диде карты, ишектән керә-керешли. – Бар, тиз генә мунча тергезеп җибәр. Бер кочак утын белән генә.

– Әстагы, зерә вакытта ниткән мунча ул тагын?

– Зерә вакыт түгел. Иртәгә унга Мәрзияләргә барасы. Аның оныгына исем куштырырга.

– Соң, нинди оныгы бар ди аның?

– Биш яшь инде ул балага. Исеме авыр дигәннәр. Иртәгә, аш үткәреп, Лилия дип яңасын кушабыз.

– Һай Аллам, төшкән икән өстеңә бәла! Фарух мулланы бүлнискә алып киткәннәр икән дип ишеттем шул, менә сиңа да эш чыкты! Ярый, хәзер мунчаны ягып җибәрәм, иртәгә иртән тәһарәтләнеп чыгарга да җылысы калыр.

Шулай икесе дә мәшәкатьләргә кереп чумдылар. Икесе кинәт кенә яшәреп, җанланып киткән төсле булды. Шәмсекамәр карчык ялт кына итеп мунчаны тергезеп җибәрде, аннан соң, өйгә кереп, картының тәсбихын, намазлыгын табып бирде. Тегесе исә, бик киеренке кыяфәттә, иреннәрен кыймылдатып, инде онытыла төшкән догаларны кабатлый иде.

– Карале, Шәмсекамәр, ник син бер дә абыстай булып, минем белән ашларга йөрмәдең ул? – дип сорады, мунчадан кереп, урын өстенә яткач, Гарәпша.

– Ник дип… Безнең якларда андый гадәт юк бит. Син дә уҗымга яки хәмер эчәргә чыгып китмисең. Саклап йөрисе түгел. Аннан, безнең якта ул абыстайлыкны электән үк өнәп тә бетермиләр шикелле.

Ахыры бар >

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

# Хәтер начар

Хәтере начар кешене нәрсә дип атыйлар әле? Аны кем белгән инде. Әйе, «кәкә хәтер» диләр. Әллә алай димиләрме? Бераз катырак сүз кулланаларшикелле. Әллә катырак нәрсәне аңлаткан сүзме? Белмәссең инде. Шулхәтле катлаулы бу дөнья – чынлап уйлый башласаң, юк кына нәрсәнең дә очына чыгып булмый.

Ә гади генә әйткәндә болай була. Мин үзем болай начава кеше, әйбәт кеше. Тик хәтер начар. Әйбәт кеше булу бик рәхәт нәрсә инде ул. Тик менә хәтернең начар булуы... Хәтерең начар булгач, әйбәт кеше булып калу шулхәтле кыен.

Гомумән, кешеләр барысы да әйбәт булырга тиешләр. Кеше игелек кылыр өчен яратылган зат бит инде ул. Башкаларга әйбәтлек эшләү үзеңә дә рәхәт. Син, әйтик, кемгәдер игелек итәсең... Үзеңнең дә хәлең артык шәптән түгел, тик син ул хакта уйламыйсың... Син теге кешегә игелек итәсең, ә ул сөенә. Ихлас күңелдән шатлана, бахыр, дөньялыкта оҗмах тапкан сыман. Һәм аңа карап син дә сөенә башлыйсың. Аның шатлыгы сиңа да күчә. Сиңа да рәхәт була.

Менә шуларны уйласаң, кеше бер-берсенә ничек кенә булса да игелек эшләргә тиеш кебек тоела. Яхшылык кылу өчен ул бер генә мөмкинлекне дә ычкындырмаска тиеш, җай гына көтәргә тиеш кебек. Һәм кайчагында ник игелек эшләү өчен чиратлар барлыкка килми микән дип аптырап та куясың әле. Шулхәтле рәхәт бит инде ул бүтәннәргә әйбәтлек эшләү.

Менә бер көнне күрше кергән... Кергән дип... Өйгә үк кермәгән инде... Ишек төбендә дә түгел... Карале, моңарчы игътибар иткән юк иде, кеше бит хәзер берберсенә керми икән. Өенә. Чакырсаң да керми. Менә әйтеп кара син: «Күрше, әйдә безгә кер, сөйләшеп утырыйк», – дип. Ул баш тарта, әллә нинди сәбәпләр уйлап чыгара башлый. Югыйсә кер, сөйләшеп утыр, берәр чынаяк чәй эч бит инде. Юк, ул керми. «Бүген аңа керсәм, иртәгә үзенең миңа килеп җитүе бар», – дип уйламый торгандыр инде ул... Вәт менә шул күрше дә кермәгән инде... Подъезд алдында очраштык. Мин утырган эскәмиягә килеп утырды. Заманы өчен анысы да ярый инде. Син утырган эскәмиягә килеп утырган икән, кунакка килгән сыманрак тоела. Вәт шул күрше әйтә:

– Карале, синең больницада эшләүче танышың юкмы? – ди.

«Бар!» – мәйтәм. Әчтән генә. Башыңа килгән беренче уйны кычкырып әйтергә ярамый бит инде. Башта мәсьәләне ачыкларга кирәк. Нәрсә тели ул, нинди максат белән сорый. Ә бәлки ул бары тик кагыштырып карау өчен генә кызыксынадыр. «Бар» дисәң, бәлки, кәефе кырылыр. Ә «юк» дисәң... «Минем танышларым буа буарлык, ә моның беркеме дә юк!» – дип сөенүе дә бар. Ә аны сөендерергә кирәк. Үзебезнең күрше бит, чит кеше түгел.

– Нәрсә булды?

Ну аңлатып бирде инде. Гади генә икән йомышы, табибның кабул итүе генә кирәк. Аннан соң калганы минем өстә түгел. Болай гына керәм дисәң, бик озак көтәргә яки бик зур акча түләргә кирәк икән.

– Аптырап беттем инде, – ди. – Чир көчәя, бик сызландыра...

Мин шундук телефонны җыйдым да кабул итү көнен билгеләп тә куйдык. Әле үзем дә шул дус врач янына җыена идем. Бер уңайдан очрашу вакытын да килешеп куйдык. Вәт кешегә яхшылык итүнең бер кыенлыгы да юк аның. Ә күрше сөенә! Йөзләре алсуланып, хәрәкәтләре җиңеләеп киткәндәй. «Хатынны да шатландырыйм әле», – дип ишеккә атлады. Менә бит ул, малай! Аны шулай шатландыра алуым өчен үзем дә сөенеп калдым. Рәхәт инде ул...

Үзем болай әйбәт кеше мин. Тик хәтер начар. Күрше күздән югалуга хәтер тарткалый башлады. «Ә исеңдәме, теге вакытта ул ризалашмаган иде. Ә бит синең дә хәлең авыр, бик авыр чагың...» Мин хәтерне томаларга тырышам. Тик ул хатын түгел, авызыңны яп, дип булмый... Хәер, хатын да ябып булмый, ә бу аннан да яман. «Теге вакытта... – дип уҗәтләнә хәтер, – йомыш белән кергәч... Ә бит аның өчен бер ни тормый иде... Ә ул сиңа булыштымы?» Шул рәвешле колак төбендә «ә теге чакта», «булыштымы», «рәхмәт итәме» кебек сүзләр ташкыны котыра башлый. Мин бирешмим. Аның саен хәтер уҗәтләнә. Инде моңа чыдар чама юк.

Белмим, үз сүземдә кала алырмынмы. Әллә теге үтенечемне кире кагып шалтыратырга туры килерме... Әйтәм бит, хәтер начар минем. Ә начар хәтер белән әйбәт булып кала алу – газап.




Рәис Габдулла

**4 март санында чыккан сканвордның җаваплары**
**Горизонталь буенча:** черки, Вия, Госман, Сим, Гайнуллина, Шода, балет, Нури, мурт, арык, трико, чылану, мулла, каюр, Луи, нан, ант, мизан. **Вертикаль буенча:** алым, ашамлык, йолу, киез, чөгендер, ава, Уатт, Юнан, Рәсүл, тумран, Ленар, НТВ, иваси, уриал, Инин, кыр, Маликова.

## ВИКТОРИНА

**Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.**

**1 Каллиграфия сүзе нәрсәне аңлата?**

А) Көнчыгыш мөселман илләрендә көмеш акча;
Б) дәүләт җитәкчесенең сәркатибе, ярдәмчесе;
В) матур һәм төгәл язу сәнгате.

**2 Аттиланың үлеме, һуннар империясе таркалу ничәнче елда була?**

А) 802;
Б) 453;
В) 922.

**3 Чыңгыз ханның оныгы.**

А) Батый;
Б) Аксак Тимер;
В) Таҗетдин Ялчыгол.

**4 Закир Кадыйри – ул...**

А) Коръәнне татар теленә тәрҗемә иткән галим;
Б) опера җырчысы;
В) дин белгече, гарәп телчесе, тәрҗемәче, мөгаллим, тарихчы.

**Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) А; 4) В.**

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru



**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Индекс П2435**
**Тираж – 17132 данә**

**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 233



РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**



**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**



ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**



Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+